Гаиләбездә дүрт кеше: мин, әни, улым, кызым. Хатыным – Валентина. Ул мәктәптә укытучы. Мин укытучы. Безнең йортыбыз зур. Бакчада мунча.

***Задание 21.*****Расскажи о своём режиме дня по вопросам:**

1) Син иртән ишлисең?

2) Сәгать ничәдә мәктәпкә китәсең?

*4)* Өйдә нишлисең?

5) Сәгать ничәдә дәрес әзерлисең?

**Комплект упражнений для татарской группы.**

**1 нче күнегү. Мисаллар китерегез.**

Акрын һәм тыныч исә торган яз җиленең җиңел генә тибрәнүе белән әледән-әле җыерчыкланып китә торган суның, күпер баганаларына килеп бәрелеп, җиңел генә чыпылдавын һәм әллә кайдан, күлнең икенче башыннан ишетелә торган скрипка тавышының кайсыбер кисәкләрен тыңлый-тыңлый, Аляны көтәргә тотындым: күзләрем ул киләчәк юлны сагалыйлар иде. (Ф.Әмирхан)

мисаллар кайсы стильгә карый? (Дәфтәрдә эш).

1. Стиль сүзен сез ничек аңлыйсыз?

2. Сез нинди стильләрне беләсез?

**2 нче күнегү. Өзекләрне дөрес интонация белән укып чыгыгыз.**

Билгеле, мондый вакытта балыклар яхшы чиртәләр, кармакны бер дә тик тотмыйлар. Таҗиның этисе балыкларны сөйри дә чыгара, сөйри дә чыгара, ялтырап торган ап-ак чабакларны*, көмеш тәңкәле кызылканатларны, әрсез алабугаларны. Таҗи аларның барысын да чиләккә җыя бара. Менә инде аларның балык сала торган чиләкләре дә тулып килә. Төшлеккә җитә башлагач, кояш бик нык кыздырырга тотынды. Монысын Таҗи да тойды, этисе дә. (А.Алиш)

Киң колач белән башланган киң, салмак интонация бер бөтен булып төгәлләнсен, түгәрәкләнсен өчен, берсе янында берсе һәрберсе үзенчә һәм мәгънәне, һәм эмоциональ тәэсирлекне тагын-тагын үстерә, көчәйтә торган тиңдәш кисәкләр тезелеп китә. (С.Ибраһимов)

чабак – карплар семьялыгыннан төче суда яши торган зур булмаган балык (плотва).

**3 нче күнегү. Өзекне укып, сөйләмә стильнең үзенчәлекләрен аңлатыгыз.**

Йомышым юк дип әйтүен әйткән идем дә, Фатих абый, — дип, шактый ук олы сыман күренергә тырышып, янә сүз башлады бу икенче килүендә, — ә йомышым булганны әйтмәдем, оялдым... Дөресен генә әйткәндә, йомышым шул, Фатих абый, мин быел ун сыйныфны бетердем, даром что шулай чүрәкәй үрдәк кенә булыйм. Хәзер инде аптыраган, мәктәпне отличнога бетердем, аттестатым да отлично, ә менә баш каткан: дальше кайсы уку йортының ишеген кагарга икән? Кагаргамы? Әллә күмәк хуҗалык эшендә генә калыргамы? Укып чыккач

**4 нче күнегү. Текстны укыгыз. Публицистик стильгә хас билгеләрне әйтегез.**

…Чүл буйлап ике кеше бара. Алар үзара бәхәсләшеп китәләр һәм берсе икенчесенең яңагына сугып җибәрә. "Миңа бүген дустым яңагыма сугып җибәрде,"- дип язып куя тегесе комга. Болар бара-бара оазиска килеп чыгалар. Шунда елга күреп, су кереп чыгарга булалар. Теге яңагына эләккәне батып үләм дигәндә, аны дусты коткарып кала һәм ул: "Мине бүген дустым коткарды," — дип, ташка уеп язып куя. Шуннан теге яңагына сугып җибәргәне: "Син нишләп мин сукканны комга яздың, ә коткаруымны - ташка?" — дип сорый. Дусты аңа җавап бирә: "Безне кемдер рәнҗетә икән, без аны комга язарга тиеш. Чөнки җил аны очыртып алып китә. Ә кемдер безгә яхшылык эшли икән, без аны ташка уярга тиеш: игелек, яхшылыкны берни дә җил алып китәргә тиеш түгел".

Мин язмамны тиккә генә шушы гыйбрәтле хәлдән башламадым. Укытучы хезмәте комга языла торган хезмәт түгел, ул хикәяттә әйткәнчә, ташка язылган төсле, бала күңеленә уелып калырдай эшләр башкарырга тиеш. Дөньяга, барлык кешеләргә, күренеш-вакыйгаларга күңелең аша, изгелек белән карарга өйрәтә ул укытучы. (Г.Р.Галимҗанова язмаларыннан)

**5 нче күнегү.Көндәлек матбугаттан бер мәкаләгә анализ ясагыз. Публицистик стильгә хас үзенчәлекләрне атагыз.**

"Безне кемдер рәнҗетә икән, без аны комга язарга тиеш. Чөнки җил аны очыртып алып китә. Ә кемдер безгә яхшылык эшли икән, без аны ташка уярга тиеш: игелек, яхшылыкны берни дә җил алып китәргә тиеш түгел" дигән җөмләне сез ничек аңлыйсыз? Мисаллар белән дәлилләгез.

**6 нчы күнегү.Өзекне сәнгатьле итеп укыгыз. Татар телендә җөмләдә сүз тәртибен искә төшерегез. Кайсы җөмләләрдә сүз тәртибе сакланмаган?**

Август аеның җылы, кояшлы көннәре. Быел табигать авыл кешесенә мәрхәмәтле булды, урып-җыю вакытында нәкъ шундый аяз көннәр кирәк тә инде. **Тик бар дөнья тузанга чумган, коры, эссе һава тынга каплана.** Юл буендагы бу бичара каен да тоташ тузанга күмелеп утыра. Арыган, әлсерәгәндер инде мескенкәем. Ничә еллар буена Шатлык кешеләрен каршылый - озата ул.

*(М. Хуҗин)*

**7 нче күнегү.Түбәндәге җөмләләрне дөрес итеп укыгыз, күчереп языгыз, аерымланган кисәкләрнең астына сызыгыз.**

1.Нәфисәләр, урман авызыннан кереп, тар сукмактан бераз барганнан соң, иренчәк агымлы кечкенә генә инешне узып, бер ачыклыкка килеп чыктылар. *(Г.Бәширов)* 2. Җитез сабан тургайлары, такмаклап биюче егетләр сыман, нурлы һавадан төшмичә, сайрый-сайрый, сызгыра-сызгыра җилпенәләр. *(Ә.Еники)* 3. Яңгыр теләп, яз хәбәрчеләре- сыерчыклар оча. *(Г.Гобәй)* 4. Сылу сыерчыклар, назлы сандугачлар, иркә кәккүкләр, туйга чакырылган җырчылар кебек,су буендагы куе тирәкләрдә туктаусыз сайрап тора. *(Ә.Еники)*5. Сабан тургайлары, язгы табигатькә иртәнге сәламнәрен җиткерү өчен, зәңгәр күккә күтәрелделәр. Алар, язны мактап, озак-озак сайрыйлар. *(Натуралист язмаларыннан)* 6. Рөкыя шактый алдан кайтып җиткән булса да, капка төбендә калып, боларны көткән.

**8 нче күнегү.Җөмләләрне укыгыз, тыныш билгеләрен аңлатыгыз.**

1. Кояш, элеккедән дә матуррак булып, болыт астыннан чыкты. *(Г.Бакиров)* 2. Ә вак балыклар, дошманнары - эре балыклардан куркып, көтүләре белән комлы сайлыкка йөзеп чыга. (*Д.Аппакова)* 3. Өч көн эчендә җир өсте яңадан тугандай булды. Һәркайда-аклык, пакьлек. *(А.Хәсәнов)* 4.Дуамал бураннары, чатнаган суыклары белән бергә кыш үтеп китте .*(Г.Ибраһимов)* 5.Кояш югарырак үрләде, юкәне буеннан-буена яктыртты. *(М.Рафиков)*

**9 нчы күнегү. Җөмләләрне татарчага тәрҗемә итеп языгыз. Бу җөмләләрдә нинди тыныш билгесе җитми? Татар телендә ул кайсы очракларда куела?**

1.Июньская ночь коротка. *(Г. Троепольский)* 2.Звезды великолепны. *(И.Гончаров)* 3.Пурга это снежный буран во время которого температура понижается до минус пятнадцати. *(В.Арсеньев)* 4.Точность и краткость- вот первые достоинства прозы.*(А.Пушкин)*5.А вы человек бывалый. *(А.Чаковский*)6. Художественная литература это искусство слова. *(К.Федин)* 7.Коса девичья краса.*(Пословица)*8. Лось очень сильное осторожное и умное животное. (И.Соколов-Микитов) 9. Доброе начало половина дела. *(*

**10 нче күнегү. Җөмләләрне бәйләнешле текст барлыкка килерлек итеп урнаштырыгыз.**

1. Миңа да бик авыр иде. 2. Үзе дә сизмәстән, очраклы рәвештә генә юлыма тап булган бу абзый миңа «яшәү мәгънәсе», «иманлылык» төшенчәләрен үз эченә алган һәм алдагы гомеремдә мең мәртәбәләр ярдәмгә киләчәк рухи ныклык, ихтыяр көче биреп киткән иде... 3. Шушы хатирәләреннән бушанган фронтовик карт кабат, тыйнак кына елмаеп, моңсуланды, басынкыланды, уйчанланды... 4. ...Әллә нинди булды ул көн. (Г.Гыйльман)

**11 нче күнегү. Өзекне дөрес һәм сәнгатьле итеп укыгыз, кыз озату күренешен кыскача сөйләп бирегез.**

Акрын һәм тыныч исә торган яз җиленең җиңел генә тибрәнүе белән әледән-әле җыерчыкланып китә торган суның, күпер баганаларына килеп бәрелеп, җиңел генә чыпылдавын һәм әллә кайдан,

күлнең икенче башыннан ишетелә торган скрипка тавышының кайсыбер кисәкләрен тыңлый-тыңлый, Аляны күтәргә тотындым: күзләрем ул киләчәк юлны сагалыйлар иде. (Ф.Әмирхан).

**12 нче күнегү. Текстны сәнгатьле итеп укыгыз. Тезмә кушма җөмләләрне табыгыз һәм аларның төрен билгеләгез. Аларның үзара нинди чаралар ярдәмендә бәйләнүен ачыклагыз.**

Көймәче тагын мотор бавын тартты. Мотор төчкерде, пошкырды да янә сүнде, Хуҗаның түземлеге төкәнде.Мотор төчкереп алды да тырылдап эшләргә кереште. Көймәгә беренче Хуҗа сикереп менде, аның артыннан ярдәмчесе үрмәләде, аннан соң Мөхәммәтләр утырышты. Көймәче сүзен әйтер алдыннан, әүвәл күккә күз ташлады, аннары аның күз карашы көймәдән читкә чабышкан дулкыннар өстеннән сикереп узды. Ул янә күккә карады. Болытлар бик тиз хәрәкәт итә, күктә Зур Судагы дулкыннар чагыла. Көймә чайкалып китте, мотор сәер тавыш чыгарып пырхылдады... Хуҗа кеше малайны кырыйдан каерып алды, аның ярдәмчесе белән көймәче карт Мөхәммәтнең әтисенә көймәгә менәргә булыштылар. Хуҗа аңа кырын күзе белән генә карап куйды, Мөхәммәтнең әтисе бу караштан куырылып килде. Мулла бабай медер-медер капчыклы карт белән сөйләшә, дөресрәге, үзе генә сөйли... Җир өстен су баса, коры җир тарая.Мулла бабайның тавышы бик зәгыйфь чыкты, аның гәүдәсе бөтенләй бөрешеп, кечерәеп калган иде... Теге чаклардагы чыра яктысы, сукыр лампа яктысы синең күзеңне бетергән, күрмисең син, менә шул!Мөхәммәт атлы малайның күзләре елтырап китте, ирексездән авызы ерылды. Су өстендәге дулкыннар ишәйде, көймәгә берөзлексез шап та шоп сугып торган кара сыртлы дулкыннар зурайганнан-зурайды... Аның беләкләре көч белән тулды, ул ашыга-ашыга иште. *(З.Хөснияр*)

**13 нчы күнегү.Мәкальләрне укыгыз, мәгънәләрен аңлатыгыз. Кушма җөмлә тәшкил иткәннәрен дәфтәрегезгә күчереп языгыз. Кушма җөмләләр составындагы гади җөмләләр нинди мәгънә мөнәсәбәтендә торалар һәм нинди чаралар ярдәмендә бәйләнгәннәр, шуны ачыклагыз.**

1. Ашның мае бар, сүзнең җае бар. *(М.)* 2. Кунак килсә, ит пешә, ит пешмәсә, бит пешә. *(М.)* 3. Күлнең күрке - камыш, ирнең күрке - намус. *(М.)* 4. Яхшы гадәт адәм итәр,яман гадәт әрәм итәр. *(М.)* 5. Ялагайның күзе ─ көзге, теле ─ тасма. *(М.)* 6. Күмәк эш күңелле эш .*(М.)*7. Адәмне адәм иткән әдәп. *(М.)*

**13 нчы күнегү.**

1. Ә.Еники кайчан һәм кайда дөньяга килгән?
2. Язучы кайчан Казанга килә?
3. Сугыш темасын әдип кайсы әсәрләрендә чагылдыра?
4. Аның кайсы хезмәте дәүләт бүләгенә лаек булган?

**14 нчы күнегү.**

Биремнәр:

1.Х.Туфанның татар поэзиясендә тоткан урыны турында сөйләгез.

2.Шагыйрьнең “Агыла да болыт агыла”, “Илдә ниләр бар икән”, “Кайсыгызның кулы җылы”, Очрашырбыз әле” шигерләре турында фикер алышыгыз.

**15 нчы күнегү.**

1. Түбәндәге мәкальләрнең мәгънәләрен аңлатыгыз:

Агачны яфрак бизәсә,кешене хезмәт бизи.

Осталык иң зур байлык.

Өйрәнмичә хезмәт юк, хезмәт ... хөрмәт юк.

һөнәрле үлмәс,һөнәрсез көн күрмәс.

## КРИТЕРИИ ОЦЕНИВАНИЯ ЗАДАНИЙ

**Оценка «5» (отлично) – 90% правильных ответов**
из 10 тестов 9 правильных ответов
из 15 тестов 14 правильных ответов
из 20 тестов 18 правильных ответов
из 30 тестов 27 правильных ответов
из 35 тестов 31 правильных ответов
из 50 тестов 45 правильных ответов
из 100 тестов 90 правильных ответов

**Оценка «4» (хорошо) – 80% правильных ответов**
из 10 тестов 8 правильных ответов
из 15 тестов 12 правильных ответов
из 20 тестов 16 ответов правильных
из 30 тестов 24 правильных ответов
из 35 тестов 28 правильных ответов
из 50 тестов 40 правильных ответов
из 100 тестов 80 правильных ответов

**Оценка «3» (удовлетворительно) – 70% правильных ответов**
из 10 тестов 7 правильных ответов
из 15 тестов 11 правильных ответов
из 20 тестов 14 правильных ответов
из 30 тестов 21 правильных ответов
из 35 тестов 24 правильных ответов
из 50 тестов 35 правильных ответов
из 100 тестов 70 правильных ответов

**Оценка «2» (неудовлетворительно) - 69% правильных ответов**
из 10 тестов 6 правильных ответов
из 15 тестов 10 правильных ответов
из 20 тестов 13 правильных ответов
из 30 тестов 20 правильных ответов
из 35 тестов 23 правильных ответов
из 50 тестов 34 правильных ответов
из 100 тестов 69 правильных ответов

## 2.5. Тексты для анализа.

**Проверяемые результаты обучения:** Проверяем навыки сопоставительного анализ. Студенты должны уметь правильно сопоставлять соотношения восточной, русской классической и западной литературы и литературных традиций в произведениях татарских писателей.

### Тексты для татарской группы

### Текст 1

### Дастаннар һәм аларның барлыкка килүе

«Дастан» − фарсы сүзе. Төрки телләрдә ул «тарих, хикәя», «үткән эшләр хикәясе» мәгънәсендә йөри. Дастан − гадәттә, әкият сюжетларын, риваять-легендаларны әдәби эшкәртеп язган әсәр. Ул проза яки шигырь белән, яисә һәр икесе аралашып язылган булырга мөмкин. Н. Исәнбәт дастанга түбәндәге мәгънәне бирә: «Дастан бездә «эпос» дигән мәгънәне дә, «поэма» дигән мәгънәне дә үз эченә ала. Шуның белән бергә, халык иҗаты өчен хас булган «эпик поэма» дигән мәгънәне аңлатуы белән дә бу атама сүз үз урынында әйтелгән була. Ул русчадан «былина» мәгънәсен дә үз эченә ала».

Дастаннар аерым шагыйрьләр һәм башкаручылар тарафыннан буыннан-буынга тапшырылып килгән. Мондый кешеләр төрле халыкта төрле − манасчы, акын, ашуг, чичән, җирау, дастанчы һ.б. исемнәр белән аталып йөртелгәннәр. Дастаннар, татар халык иҗатында гасырлар дәвамында сикәлтәле юллар узып, төрле үзгәрешләр кичергәннәр. Шулай да алар, халыкның югары гуманистик идеяләрен, сәнгатьчә матурлыкны гәүдәләндерүче әсәрләр буларак, хәзерге, көннәргәчә сакланып калганнар. Алар бүгенге көндә дә язучы, шагыйрь, драматургларга яңа әдәби әсәрләр тудыруга нигез булып торалар. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», М. Җәлилнең «Алтынчәч», Н. Исәнбәтнең «Идегәй» әсәрләре шундыйлар рәтендә тора.

Бер генә халыкның әдәбияты да халык тормышыннан аерым яшәми. Ул халык тормышын чагылдыра. Шуңа күрә халык әдәбиятында, мәдәниятендә патриотизм (ватандарлык), гуманизм (кешелеклелек) сыйфатлары бу җирлектә барлыкка килмәгән, дип әйтә алабыз.

Татар дастаннары өч төркемгә бүленә:

1.Тарихи дастаннар («Җик-Мәргән», «Чура батыр хикәяте», «Идегәй» һ.б.). 2. Алыплар (батырлар) турында хикәятләр («Мәшәк алып», «Кара күңел», «Ак күбек» һ.б.). 3. Мәхәббәт дастаннары («Түләк», «Йосыф китабы», «Таһир белән Зөһрә», «Ләйлә белән Мәҗнүн» һ.б.).

### Текст 2

### «Идегәй»дастаны

Дастан каһармансыз булмый. Халык телендә аларны батыр дип йөртәләр. Зур батырларны зур вакыйгалар тудыра. Зур вакыйгаларда халык ягыннан торып көрәшкән һәм шул юлда гадәттән тыш эшләр күрсәткән кеше халык каршында батыр булып санала. Менә шундый зур батырларның тууы, үсүе, гадәттән тыш батырлыклары һәм зур көрәшләрдә корбан булуы турында халык телендә төрле хәбәрләр, җырлар, легендалар, дастаннар таралган. Шуларның берсе − «Идегәй» дастаны. Ул героик эпос рәтенә керә. Героик эпосның төп темаларыннан берсе булып илне, халыкны илбасарлардан саклау темасы санала. Героика темасы әкиятләрдә дә очрый. Ләкин дастаннар әкиятләрдән аерылып торалар. Хәлиткеч рольне биредә, беренчедән, героика уйный. Батырлык дастан героеның илен, ыруын, гаиләсен саклау темасын ача. Икенчедән, әкиятләр уйдырмага нигезләнгән. Ә дастаннар бик күптәнге, әмма чынбарлыкта, асылда булган ниндидер чын вакыйгаларны сөйләргә вәгъдә итәләр, чыганакларга таяналар. Өченчедән, татар дастаннарының вариантлары күп төрки халыкларда бар. Н. Исәнбәт «Идегәй» дастанының татарларда − 18, башка халыкларда 34 варианты барлыгын әйтеп үтә.

Н. Исәнбәт, «Идегәй» дастанының барлыкка килүенә XIV йөзнең ахырында һәм XV йөзнең башларында Алтын Урда дәүләтендәге эчке зур чуалышлар, Идегәй баш күтәрүе дип билгеле булган халык кузгалышлары сәбәп булган, дип аңлата. Дастанның нигезендә халыкның хөрлек һәм иминлек, бәхетле һәм тату тормышы хакындагы идеаллары ята.

Әсәрнең төп герое Идегәй – реаль герой, 1419 елда Алтын Урдада сарай аристократиясенә каршы сугышта үтерелгән бик билгеле, тарихи шәхес.

Алтын Урданың эчке хәле турында ул заманнарда Идел буена чаклы килеп йөргән гарәп тарихчылары күп кенә кызыклы нәрсәләр язып калдырганнар. Идегәй турындагы төрле легендалар ул үзе исән вакытта ук халык авызыннан сөйләнгән. Замандашы Ибне Гарәпша аның турында: «Ул бодай төсле куе коңгырт чәчле, гәүдәсе белән нык, баһадир, мәһабәт бөек күренешле, юмарт һәм гүзәл, елмаючан, үткен һәм җитез фикерле, галим һәм Фазыйлларны сөюче, ярлыларга һәм яхшы кешеләргә якын булучы, алар белән йомшак тел һәм нечкә ишарәләре белән уен-көлке сөйләүче иде»,– дип язып калдырган.

Идегәй турында дастанның үзеннән дә шактый мәгълүматлар алып була. Идегәй – Котлыкыя би углы. Ә Котлыкыя үзе Туктамыш ханның ау кошларын караучы бер кеше булган. Аксак Тимер белән бәйләнешкә кергән өчен, Туктамыш хан аның башын чаптырган, нәселен бетерергә тырышкан. Бу карарны ишеткәч, аның нәселен калдыру өчен, Котлыкыяның якын кешесе Җантимер бишектәге Идегәйне үз баласы Кобогыл белән алыштыра.

Идегәй, ничә еллар буе Кобогыл исемендә үсеп, хан сараенда түрә була. Идегәй бала чагында ук көчле, ярдәмчел, зирәк, тапкыр була. Бу сыйфатлары белән ул башкалардан аерылып тора. Шушы сыйфатлары Туктамышны үзенә җәлеп итә һәм ул аны сараена алдыра. Аңа Айтулы атлы чибәр кызны бирә. Идегәй ханга хезмәт итә башлый.

Кырымнан кыен дау килсә,
Дауны кырды Идегәй;
Кырымнан калын яу килсә,
Яуны кырды Идегәй.

Идегәй аркасында Туктамыш төрле яулардан котыла, байлыгы, коллары көннән-көн арта бара.

Биләгәне кол булды.
Әйдәгәне мал булды;
Җәеп салсаң көмешен –
Җәйрәп яткан күл булды...

Соңга таба Идегәй Туктамыш сараенда сул кул би (сул канат түрәсе) булып эшли башлый. Ягъни Иделнең сул ягындагы хөкем эшләре (Болгардан алып Урал һәм Иртыш буйларына чаклы) аның карамагында була. Ханбикә Иәникәнең Идегәйнең абруе үсүгә ачуы килә һәм ул ире Туктамышны аңарга каршы котырта башлый. Ләкин Туктамышның бу сүзләргә ышанасы килми:

Өрәге миннән каты булса да,
Кобогыл миңа үч булмас, —
Синең дигән һич булмас,
Һич булмас, ай, һич булмас!

Ниһаять, Туктамыш Идегәйнең кем икәнлеген әйттерү өчен, ил карты – 190 яшьлек Субраны чакырта. Ул:

Күп батырны мин күрдем,
Күп батырны мин белдем,
Яшем йөз туксанга килгәндә,
Кобогылдай ирне мин
Бер күрмәгән картыңмын! –

дип җырлый һәм киләчәктә аның Туктамышның башына җитәчәк кеше булачагын әйтә.

Идегәй үзенә каршы болытлар куерганын аңлый һәм Сарай шәһәрендәге Аксак Тимер ягына качып китә. Аңа Җантимернең биш улы да иярә. Аларны куа килгән Җанбай белән Идегәй арасында кызыклы гына сөйләшү була. Идегәйне кире борылырга өндиләр, байлык вәгъдә итәләр. Идегәйнең карары нык.

– Таймам баскан юлымнан,
Салмам сөңге кулымнан,

Салмам калкан иңемнән,
Яу җыярмын илемнән.

Шулай итеп, Идегәй Аксак Тимер янына качып китә һәм озакламый, Аксак Тимер гаскәре белән берлектә, Алтын Урданы килеп басып ала. Идегәй Аксак Тимер белән дә калмый. Ул бары тик аның гаскәреннән генә файдалана. Туктамышны ул башкача җиңә алмас иде. Идегәй Аксак Тимер белән китми, Алтын Урдада кала. Туктамыш хан үлмәгән, җиңелгән генә була. Идегәй Алтын Урданың үз халыкларын Туктамышка каршы күтәрә. «Бу сугышта, − дип яза Н. Исәнбәт, − коллардан алып Алтын Урданың дәүләт системасыннан риза булмаган киң катлау халык Идегәй артыннан китеп, бу хәрәкәт киң халык кузгалышы төсен алды. Безнең өчен бу кузгалышның иң әһәмиятле җире дә шунда, һәм Идегәйнең халык каһарманы булып танылуының сере дә шушында булырга тиеш». Идегәйгә бу кузгалышның башында тору җиңел түгел, әлбәттә. Аңа каршы төрле интригалар оештырыла. Аңа каршы хәтта улы Норадынны да котырталар. Бу урында Идегәйнең Норадын белән очрашып сөйләшүе гыйбрәтле. Норадын, коткыга бирелеп, этисенә каршы чыга, үзе үскән төбәкне, халыкны рәнҗетә. Бу эшләре өчен этисе аны каты кисәтә:

Киң болынны яндырдың,
Кайдан үлән табарсың?
Кара суга кан койдың,
Суны кайдан эчәрсең?

Тарихтан билгеле булганча, 1391—1398 еллар эчендә Идегәй белән Туктамыш арасында 16 мәртәбә сугыш булган. 15 нче мәртәбәсендә Идегәй яхшы ук каты җиңелгән, шуннан сон 6 ай буена каядыр югалып торган, аның эзе дә беленмәгән. Бу хәл үзе үк Идегәйнең, халык тарафыннан яшерелеп торып, уналтынчы мәртәбә гаскәр җыярлык үз кеше һәм танылган батыр булуын күрсәтә. Туктамыш инде тынычландым дигәндә, 1398 елда Идегәй, гаскәре белән һөҗүм итеп, аны җиңгән. Шуннан соң Туктамыш, Идегәй белән сугышкалап торса да, җиңүгә ирешә алмый, аны 1405 елда Идегәйнең улы Норадын үтерә.

Әсәрне өйрәнү барышында Идегәйнең чын батыр икәнен күрдек, ләкин әсәрнең халыкчан булуының, халык арасында телдән-телгә күчеп килүенең башка сәбәпләре дә бар. Шуларның берничәсенә тукталып үтәбез.

1. Идегәй − халык күрергә теләгән батыр. Ул коллыкка каршы күтәрелә, көчсезләргә ярдәм кулы суза. Мәсәлән, Аксак Тимер кызы Акбеләкне көчләп алып киткән Кара Тиен кулыннан коткарып, 40 колны азат итә.

2. Идегәйнең характер сыйфатлары халык идеаллары белән туры килә.

3. Идегәйнең теле − халык теле. Ул үз сөйләмендә халык мәкальләрен, әйтемнәрен оста куллана.

4. Дастанда ата белән ул мөнәсәбәтләренә зур урын бирелгән. Идегәй үз улын бик ярата. Норадынның үзенә каршы күтәрелүен күргәч, ул аңа үз улын яхшы кеше итеп үстерү өчен ниләр эшләвен сөйләп бирә. Аның өчен берни дә кызганмаган ул. Норадын боларны аңларга теләми. Ул шуңа барып җитә ки, Туктамыш хан кызлары өчен кычкырышып, этисенең бер күзен чыгара. Бу хәл Идегәйгә бик авыр тәэсир итә. Күз карасыдай күргән баласы аның күзен чыгарсын әле...

Син дигәндә җан аткан
Ялгыз атаң мин идем,
Күзем орып чыгардың;
Кайда барып уңарсың?
Языгы белән гөнаһсын,
Кайда ла барып йоларсың? −

дигән сүзләре белән Идегәй ата-анасын рәнҗеткән кешенең бервакытта да рәхәт күрмәячәгенә ишарә ясый:

Каргышым кара таштан үтәдер.

Норадынга этисе акыллы киңәшләрен бирә. Аңа халык белән бергә булырга, халыкка таянырга куша:

Нинди юан булса да,
Яңгыз агач өй булмас;
Нинди ятим булса да,
Яңгыз егет би булмас.

Ләкин Норадын бу сүзләргә артык игътибар итми, ә үз көченә таяна. Идегәй улын сагына, аның бөтен гөнаһларын кичерергә әзер. Ул, аны чакырып, илчеләрен җибәрә.

Норадынның әнисе белән булган әңгәмәсе дә гыйбрәтле. Әнисе дә аңа халыктан аерылмаска киңәш итә:

Халык белән даулашып,
Яхшыны кайдан табарсың?

5. Әсәрнең буеннан-буена кешеләргә мәрхәмәтле булу, кешелеклелек күрсәтү идеясе сузылган. Моның иң ачык мисалы − Идегәй тарафыннан Норадынны үгетләргә килгән мулланың вәгазе. Ул 10 вәгазь бүгенге көндә дә һәркем өчен, һәр халык өчен тормыш кагыйдәсе була ала. Без, әсәрне укыгач, чынлап та, ата-анасының сүзен тыңламаган, аларның сүзенә каршы килгән кешеләрнең күп бәлаләргә юлыгуын күрәбез. Норадын эти-әнисенең сүзен тыңламыйча чыгып китә һәм күп бәлаләргә юлыга. Ә ата-ана, гадәттә, баласы нинди генә булса да, аның турында кайгыртып яши. Улының бәлагә тап булуын ишеткән Идегәй дә аның янына, Иделнең икенче ягына ашыга. Норадын исә этисеннән гафу үтенә һәм озакламый яраларыннан бик күп кан агудан этисе алдында егылып үлә.

6. Дастанда гасырларга сузылган халык традицияләренә зур урын бирелгән. Мәсәлән, бала тугач үтәлә торган йолалар, өлкәннәрдән киңәш сорау (Субра карт җырулары), сугыш алдыннан баһадирлар көрәше, халык әйтемнәре, муллалар вәгазе һ.б.

7. Дастанда укучыны мавыктыра торган әкият алымнарына зур урын бирелгән. Идегәй белән Туктамыш улы Кадыйрбирденең сугышуы әкият баһадирларының сугышын хәтерләтә.

«Алып батман чукмарлы» Идегәйгә «Чөдәйле балтасы» белән Кадыйрбирде ташланды һәм ул Идегәй чукмарыннан һәлак булды. Шулай итеп, Идегәй халыкны Туктамыш нәселенең изүеннән коткара. Ханның иярченнәре, Идегәйне үтереп, хан булырга омтылалар. Хан булырга омтылган 12 би Идегәй кылычыннан һәлак була. Идегәйнең батырлыгын аның дошманнары да танырга мәҗбүр була.

8. Дастанның халыкчанлыгын билгеләүче үзенчәлекләреннән иң мөһиме − халыкның туган иленә булган мәхәббәте, аны саклап калу өчен көрәшүчеләрнең җаннарын аямавы. Идегәй үзенең туган илен һәм халкын бервакытта да исеннән чыгармый. Үләр алдыннан ул дошманнарына:

− Үлем белән куркытмаң,
Курка торган уем юк!
Җирем өчен җирсенеп,
Халыгым өчен яхшы уем, −

дип мөрәҗәгать итә һәм хәтта ул үлү белән генә аңа җиңеллек килмәячәген, дәүләтенең таркалачагын әйтеп үлә. Чынлап та, Алтын Урда тиздән таркала. «Ил сүзен тоткан» Идегәйнең хыялы тормышка аша. Илгә тынычлык килә.

И Идел-йорт, Идел-йорт,
Идел эче имин йорт.

Менә шушы иминлек өчен көрәшкән Идегәй халык күңелендә җуелмаслык эз калдыра, дастан героена әверелә.

«Идегәй» дастаны − фольклор мирасыбызның биниһая гүзәл йөзек кашы. Ул − халкыбызның милли үзаңын, тарихи хәтерен һәм ватандарлык тойгыларын шагыйранә илһам белән сугара торган бөек әсәр...» − дип язды фольклорчы-галим Илбарис Надиров.

## Текст 3

## Салих бабайның өйләнүе

Фатих Кәрими − мәгърифәтче язучы. Мәгърифәтчеләр әдәбиятның төп максатын кешеләрне тәрбияләүдә күргәннәр, халыкка аң-белем бирергә омтылганнар. Мәгърифәт ярдәмендә кешеләрнең холкын төзәтеп була, нәтиҗәдә һәркем бәхетле яши торган җәмгыять төзелә дип ышанганнар, шул ышанычны әсәрләрендә дә төп фикер итеп үткәргәннәр.

Ф. Кәриминең 1897 елда язылган «Салих бабайның өйләнүе» хикәясе әхлак мәсьәләләрен

күтәрә, татар прозасында балалар әдәбиятын һәм хикәя җанрын башлап җибәрә. Хикәя тормыштан алып язылган дигән тәэсир калдыра. Әсәрнең төп герое − гади авыл егете. Салихның яшь чагыннан алып олыгайганчы яшәгән гомере безнең күз алдыннан үтә. Ул яшьтән үк эшләп көн күргән, картайгач та эштән туктамый − кыяр бакчасын каравыллый.

Җәй көннәрендә Салих бабай янына балалар җыела. Карт балаларны бик ярата. Бабайның карчыгы үлгән, балалары читтә яши. Аңа ялгызына күңелсез. Шуңа ул һәрвакыт кеше арасында булырга тырыша. Балаларны кыяр белән сыйлый. Аларга башыннан үткәннәрне сөйли. «Безнең Салих бабай һәр хикәянең башын үзенә махсус аерым сүзләр илә башлаганлыгы шикелле, ахырын да бик килештереп хәтем итә торган иде». Үзенең тәмле, шаян теле белән балаларны үзенә карата. Алар аны тын да алмыйча тыңлыйлар, кабат-кабат сөйләтәләр. Бабай исә бераз ялындыргандай итә дә, тагын сөйли башлый.

Салих бабайның хикәяләре тормыштан алынган. Ул балаларга гыйбрәтле хәлләрне сөйли. Үзе «бик тәүфыйклы, истикамәтле (намуслы) бер карт булып, гамәл һәм гыйбадәтенә бер дә кимчелек китерми, хыянәттән бик курка торган кеше». Шулай булса да, аның яшьтән башланган бер яман гадәте бар. Ул әфьюн, борын тәмәкесе куллана. Бу эшенең начар икәнен дә белә, ләкин ташлый алмый. Балаларны яман гадәтләргә өйрәнмәскә өнди. «Әй балам, балам! Яман гадәтләргә өйрәнүдән яшь вакытта бик сакланырга тиеш икән»,− ди, үзенең бу гадәтен ташлый алмавына борчыла һәм үкенә.

Салих бабай үзенең өйләнү вакыйгасын бик тә мавыктыргыч итеп сөйли. Бервакыт ул бер иптәше белән күрше авылга кунакка барырга чыга. Юлда, күпердә, аларга ике яшь-яшь кыз очрый. Егетләр кызлар белән уен-көлке сүз алышалар. Шул очрашуда бер кыз Салихның күңеленә кереп кала: якынрак танышасы, күрешәсе, кем икәнен беләсе килә аның. Җае да чыга, койма аркылы кызның кем беләндер сөйләшкәнен ишетә. Яшьләр койма аркылы берничә көн аралашалар, сөйләшәләр. Салих кызга үзенең солдатка алыначагын әйтә. Алар бер-берсенә көтәргә вәгъдә бирешәләр. Егет 3 ел буе солдат хезмәтендә була. Кыз вәгъдәсендә тора: егетне көтеп ала. Бер-берсен сөйгән ярлар өйләнешәләр, гомер буе бәхетле тормыш итәләр. «Бөтен гомеребез буенча, бер-беребезгә хәтер калдырышу түгел, каты сүз дә әйтешмәдек»,− ди Салих бабай.

Хикәядә бабайның француз романнарын да белүе турында әйтелә. Болары инде, билгеле, мәгърифәтче язучы сүзләредер.

Автор хикәясендә бәхет мәсьәләсен дә күтәрә. Аның фикеренчә, тәрбияле, укымышлы, динле кеше бәхетле була ала. Бәхет тагын да тулы булсын өчен, яман гадәтләрдән сакланырга кирәклеге дә әйтелә.

Салих бабайның хикәясен тыңлаган балалар үзләрендә аның яхшы сыйфатларын булдырырга тырышырлар кебек. Ә үрнәк алу өчен матур сыйфатлар шактый. Бүгенге көн яшьләренә хатын-кызларга фәрештә итеп карау, кеше белән күркәм аралаша белү, дөнья әдәбиятыннан хәбәрдар булу, вәгъдәндә тору кебек сыйфатлар җитешеп бетми. Димәк, хикәя бүгенге көн өчен дә бик урынлы. Ул безгә рухи байлык, дөрес тәрбия үрнәге бирә.

## Текст 4

## Галиябану һәм Хәлил − иске гадәт-йола корбаннары

М. Фәйзинең «Галиябану» драмасы татар сәхнәсендә 1916 елдан бирле куела һәм яратып карала. Драманың үлемсезлеге, минемчә, аның мәхәббәт өчпочмагына корылуында һәм музыкаль булуында.

«Галиябану» драмасында гадәттән тыш шәхесләр, гадәттән тыш вакыйгалар алынмый. Сюжеты да гади генә: егет (Хәлил) белән кыз (Галиябану) бер-берсен яраталар, алар арасына өченче берәү (Исмәгыйль) килеп керә. Шушы нигездә генә корылса, драма беркемне дә дулкынландырмас иде. Автор кызыксындыруның башка якларына да туктала, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне дә, байлык мәсьәләләрен дә китереп кертә.

Драманың төп геройлары − Галиябану белән Хәлил. Галиябану − гади авыл кызы. Аның иң зур теләге − сөйгән егетенә кияүгә чыгып, бәхетле булу. Аның авылның башка кызларыннан аермасы юк диярлек: алар кебек үк киенә, эшен эшли, җиләккә йөри, көянтәләп су китерә, чигү чигә, шатлана, кайгыра, әти-әнисенең сүзеннән чыкмый. Бераз аермасы да бар-барын. Галиябану − үз

авылында гына түгел, тирә-якта да чибәрлеге белән дан казанган кыз. «Менә кыз дисәң кыз, чәчрәп тора, − ди яучы карчык Бәдига. − Уңган, җитез. Ул төс дисәң, юлыңда башыңны җуярлык». Атасы Бәдри дә искәртә кызының төсен, буен, акылын, белемен, җитезлеген. Ярлы кызы булса да, авылның зур бае, матурлыгына кызыгып, Галиябануга өйләнергә йөри. Авыл егетләре кызга күз өстендә каш итеп карыйлар, аңа «сандугач» дип исем кушалар. Әлбәттә инде, бөтен яктан килгән кызның бәхете булырга тиеш.

Галиябануның сөйгәне − авылның ярлы егете Хәлил. Автор аны «урта хәлле» ди, киемнәре дә әйбәт кенә: «аягында ыспай итек, каплавыч яка, итәкләре чигелгән күк сатин күлмәге өстеннән төймәләми генә простойрак пиджак кигән». Бәдига карчык аның турында: «Хан кызын димләсәң дә, оят китермәслек егет»,− ди. Хәлилнең сүзләре, үз-үзен тотышы, гадәт-холкы да яучының сүзләрен раслап тора. Авылда ул беренче гармунчы. Шулай ук Галиябануны өзелеп ярата.

Галиябануга өйләнергә йөрүче икенче бер егет − Исмәгыйль. Автор аны: «Күп җир биләүче бай егет»,− дип таныштыра. Исмәгыйль дә чибәрлеге, җорлыгы ягыннан кешедән ким түгел. Үзенең бай булуын, көчле булуын туры килгәндә искә төшерергә ярата. «Минем исемем ишетелгәндә,− ди Исмәгыйль үзе турында, − бөтен тирә халкы тетрәп торалар. Минем бөтен авыл халкын бармагымда уйнатырга кулымнан килә». Әнә шушы кеше, Галиябануны үзенә алырга теләп, ике яшь йөрәкнең бәхетенә аркылы төшә. Бу эшен ахырына җиткерү өчен, ярдәмгә Галиябануның әти-әниләрен тарта. Бәдри − Галиябануның әтисе бик теләп булыша. Чөнки аның кулына күп акча, байлык керәчәк. Кызының бәхете икенче планга күчә. Иренең һәр сүзенә риза булып яшәгән Галимәбану аңа каршы чыгарга кыймый, ире белән ризалаша. Бәдри күптән инде байларның тормышына кызыгып карый. Аның да байларча яшисе килә. Талпынып та карый. Хезмәтче малай да тота. Ләкин, кая инде ул Исмәгыйльләр шикелле бай булу?! Кызын бай кияүгә биреп, Бәдри байлар табыныннан урын алырга тели. «...Урыны килгәндә (кулы белән көрәп күрсәтә) чумырыбрак калырга кирәк»,− ди ул хатынына. Башта ук дөреслекне белгән булса да, Бәдри кызын Хәлилгә түгел, Исмәгыйльгә бирергә теләр иде. Чөнки бирeләчәк мең тәңкә аның аңын томалый. Бу исә − Бәдринең бөтен хыяллары тормышка ашачак дигән сүз. Үз хыялын тормышка ашыруда Бәдригә гасырлардан килгән һәм дин белән ныгытылган тәртипләр ярдәм итә. Гаиләдә ул − ирке чикләнмәгән хуҗа. Шулай итеп, кешенең табигый омтылышы, бәхет турындагы хыяллары иске тәртипләр һәм иҗтимагый тәртипләр белән каршылыкка керде. Көчлеләр көчсезләрне буйсындырдылар, сатып алдылар. Галиябану белән Хәлил шуларның корбанына әверелделәр.

## Текст 5

## Егет кешене кыюлык бизи

Ш. Камалның «Акчарлаклар» повестен укып чыккач, мин егетлек сыйфатлары турында уйландым. Чын егет кем ул? Соравыма җавапны повестьның үзеннән таптым да кебек. Минемчә, чын егет әсәрнең төп герое Гариф кебек булырга тиеш.

Гариф − мулла малае. Тормышы хәерчелектә үткән дип әйтәсем килми. Муллаларның тормышы начар булмагандыр, һәрбер мулла кебек, Гарифны да әтисе укыткан, әнисе бик нечкә күңелле хатын булган. Иренә беркайчан да каршы килмәгән. Ире эчеп кайтса да, тавышланса да, ул дәшми, «тавыш чыгармый, бер җирдә качып, әкрен генә елый...» Нечкә күңелле, йомшак һәм итагатьле, хискә бирелүчән булуы белән Гариф әнисенә охшаган. Кара күзләре, таза гәүдәсе әтисен хәтерләтә. Әтисенең муллалык «указы» алынуы, исерткечләр куллануы, авырып китүе, үләр алдыннан балалары белән берәм-берәм хушлашуы, башларыннан сыйпавы Гарифның күз алдыннан китми. Әтисе дә йомшак күңелле булган икән бит. Тик эчүчелеккә бирелүенең сәбәбен генә аңлый алмады Гариф, ярдәм дә итә алмады, кечерәк иде шул.

Бераз үсә төшкәч, Гариф үзендә җаваплылык тоя. Ул бит гаиләдә олы бала, җитмәсә егет кеше. Гаиләгә ярдәм итү − аның төп бурычы. Гариф, эш эзләп, читкә чыгып китә, Каспий диңгезе буендагы бер балык промыселына килеп урнаша.

Егетнең тәрбияле, укымышлы булуын бик тиз күреп алалар: артель башлыгы итеп куялар. Гариф күп сөйләшми, ләкин бер эшкә дә иренеп тормый, авыр эшне үзенә алырга тырыша. Шуның өчен дә иптәшләре аны үз итәләр. Бигрәк тә Шәрәфи абзыйга ошый ул.

Гарифны тагын да таныткан бер вакыйга була. Беркөнне диңгездә давыл кузгала. Берничә

балыкчы диңгезгә кереп китә. Аларга ярдәм кирәк. Ярдәмгә беренче булып Гариф ташлана. Шәрәфи абзыйның егетне җибәрәсе килми, өлгерми кала. Гариф артыннан көймәгә тагын өч егет ташлана. Гарифның бу батырлыгын Шәрәфи абзый хупламый, юләрлек дип саный. Ләкин егетләрнең исән-сау кайтуларын күргәч, аның фикере үзгәрә. Егетләрне мактый. «Юләр бул да, егет бул!» − ди.

Бу вакыйгадан соң Гарифнең абруе тагын да күтәрелә. Хәзер инде ул Газизәгә дә башкачарак күренәчәк. Егет кешене бит кыюлык бизи. Ул бу фикерне үзенең кылган эше белән исбат итте.

**Текст 6**

**Һ. Такташ. «Киләчәккә хатлар»**

Алсу − Һ. Такташ иҗат иткән «Алсу» шигыренең герое. Автор аны чибәр, акыллы, шаян, кирәк чагында усал да була белгән кыз итеп сурәтли. Ул − студент кыз. Имтиханнар, зачетлар биреп йөри. Белемне тиз үзләштерә. Аңа сагыну хисе дә чит түгел. Ул үзенең иренә хат яза. Хатында аның тормышка, кешеләргә гашыйклыгы, ирен яратуы сизелеп тора. Яратуын, сагынуын ул шаяру формасында белдерә. Иренә, яратып, «чукынган!» дип эндәшә. Бу − вульгар сүз түгел, минемчә. Бер-берсен яратучы кешеләрнең бер-берсенә үзенчәлекле, үзләре генә аңлый торган ярату сүзләре. Алсу үзенең фотосын да җибәрә. Хәзергә хаты һәм фотосы белән юанып торырга куша. Үзенең бик бәхетле булуы турында яза. Шаяру тонында гына булса да, иренә карата көнләшүен дә белдереп куя. Шундый матур кызны башкаларга алыштырма, янәсе.

Кыскасы, Алсуның хатыннан без бу гаиләнең бик дус, саф мәхәббәт белән яшәвен күрәбез.

Һ. Такташның «Киләчәккә хатлар» поэмасы катлаулы, авыр елларда язылган. Бу елларны аңлап та бетереп булмый. Әмма Такташ яшәгән чор кешеләре киләчәккә планнар корганнар, зур өметләр белән яшәгәннәр. Чорның кыенлыклары вакытлыча гына дип санаганнар. Матур, бәхетле заманнар киләчәгенә чын күңелдән ышанганнар.

Һ. Такташ поэмасында шул чорның кайбер күренешләрен сөйләп калдырырга тели. Яңа тормыш төзү җиңел генә булмаган. Җитешсезлекләр дә шактый булган. Беренче хатта сыйнфый көрәшнең кискен булуын яза шагыйрь. Үзе яшәгән чорны ул «бөек чор» дип атый. Үзенең бары тик дөресен генә язуы турында әйтә. Ә анкеталардагы алдаулары чиновниклар өчен генә икән, чөнки:

Һәр заманның була үзенә күрә
Сволочы (каһәр суккыры)!

Һ. Такташ − илдәге үзгәртүләрнең шаһиты. Авырлык белән булса да, күмәк хуҗалыклар оештырыла. Бу эш зур каршылыклар белән бара. Шундый каршылыкны шагыйрь авылның Мохтар карты образында чагылдыра. Карт күңелендә икеләнү яши: колхозга керергәме, юкмы? Югарыдан әйтелгән һәрбер сүзгә ышанып яшәргә күнеккән карт колхозга керә. Ләкин бөтен күңеле белән бу тормышка ияләнеп бетә алмый.

Хәзер, малай, миндә ике «мин»,
Берсе менә аның коммун яклы,
Икенчесе каршы, суккин сын!

Мохтар карт атын да колхозга тапшыра, ләкин аны һаман үзенеке дип саный. Атка азыкны да күбрәк бирергә тырыша, атка суккалаган малайның якасына барып ябыша. Бервакыт аның аты үлә. Карт нишләргә белми. Җитмәсә, хатын да елый, кайгыра, Мохтарны битәрли. Шунда карт атның колхозныкы икәнен исенә төшерә. Аңа җиңел булып китә. Әмма Мохтарның өметләре акланмый. «Яхшы» тормышта ат үләргә тиеш түгел иде бит. Минемчә, шагыйрь колхозлар төзүне үзе дә хупламый. Бу фикерне Мохтар карт образы аша күрсәтә кебек.

## Текст 7

### Г. Бәширов. «Туган ягым − яшел бишек»

### Халкымның күңел байлыгы

...Дөрес юлны табу өчен, безгә үзебезнең үткәнебезне, халыкның гүзәл йолаларын, гореф-гадәтләрен өйрәнергә кирәк. Фәкать алар гына безгә дөрес юлны табарга, халкыбызга нахак бәла ягучыларга дөрес җавап бирергә ярдәм итәчәк.

*Г. Бәширов.*

Әдәби әсәрләрне укыгач, уйга каласың. Никадәр матурлык, яңалык, гыйбрәтләр! Г. Бәшировның «Туган ягым − яшел бишек» әсәрен укыгач, мине дә шундый кичерешләр биләп алды. Әсәрдә әллә нинди мавыктыргыч сюжет та юк кебек. Малай безгә үз авылында булып үткән, үзе кичергән вакыйгалар, үз авылының кешеләре, яшьтәшләре турында сөйли дә сөйли. Повестьны укыган саен укыйсы килә. Уку барышында бөек Тукаебызның «Халык зур ул, көчле ул, әдип ул, шагыйрь ул» дигән сүзләренә тагын да тирәнрәк төшенәсең. Г. Бәширов повестен халык иҗаты, гореф-гадәтләре, йолалары энциклопедиясе белән тиңләштереп була. Әсәрне әти-әниләр, укытучы-тәрбиячеләр бала тәрбияләү китабы итеп тә куллана алырлар иде.

«Туган ягым − яшел бишек» халкымның күңел байлыгын бөтен тулылыгы белән җыйнап биргән. Автор бервакытта да нәрсәнедер эшләмәскә дигән сүзләрне кулланмый. Укучы үзе нәтиҗә ясый.

Повестьның төзелешенә килсәк, ул малай исеменнән сөйләнә, ниндидер аерым вакыйгага нигезләнгән сюжет юк. Хәер, малай андый сюжетны кора да алмас иде. Ул үзенең хәтерендә уелып калганнарны бәян итә: ничек бар, шулай сөйли.

Әсәр миңа бик җиңел укылуы белән ошады. Күңелдә уелып калырлык вакыйгалар, кешеләр дә шактый. Автор үз авылының кешеләрен үзгәртмичә, үз исемнәре белән бирә. Бу хәл повестьның ышандыру көчен арттыра.

Вакыйгаларның урыны − Г. Бәшировның туган авылы Яңа Сала. Автор менә шушы авыл халкының тормышын, яшәү рәвешен, рухи дөньясын күрсәтергә омтылган. Минемчә, татар әдәбиятында халыкның рухи дөньясын шулай киң итеп тасвирлаган башка әсәр юк. Бер авыл мисалында бит әле ул! Мондый тулылык Г. Бәшировның фольклор галиме булуыннан да киләдер.

Язучы халыкның гасырлар буе җыелып килгән рухи байлыгын йола-бәйрәмнәрендә дә, гореф-гадәтләрендә дә, кешеләрнең бер-берсе белән мөнәсәбәтләрендә дә, гаилә мисалында да күрсәтә. Мәсәлән, автор татар халкының бәйрәмнәре турында яратып яза. Болар: Сабантуй, Каз өмәсе, Тула өмәсе, киндер тукмаклау, урак уру, чәчүгә, печәнгә төшү, яңгыр боткасы һ.б. Бу бәйрәм-өмәләрдә халыкның уңганлыгы, җорлыгы, таланты ачыла. Бу бәйрәм-өмәләр вакытында егетләр-кызлар бер-берсе белән танышканнар, күзәткәннәр, соңыннан оя корганнар. Халыкның үзенә генә хас йолалары да урын тапкан. Алар бик күп булган: туй үткәрү, балага исем кушу, аулак өйләр, кунак кыз килү, ат саклаулар. Болар − кеше тормышындагы онытылмаслык вакыйгалар. Ат саклауларны гына алсак та, нинди генә әкият-риваятьләрне ишетмиләр монда малайлар! Һәрбер гаиләдә балаларны олыларга хөрмәт белән карарга өйрәткәннәр. Моны алар үгет-нәсихәт юлы белән түгел, шәхси эшләре белән күрсәткәннәр. Мәсәлән, тәмәке тартма, дип әйтәсе урынга: «Шомыртлар чәчәк ата, кошлар сайрап тора. Ә Шәяхмәт шуларның бөтенесенә сасы төтен җибәрә. Тьфу»,− ди. Гомәрнең әтисе Бәшир абзый бервакытта да тик утырмый, ул һаман эштә. Балалары да аңа охшарга тырышалар. Бәшир абзый балаларының укуы белән дә кызыксына. Кычкырып китаплар укыта, китаплар алып кайта. Гаиләдә кечеләрнең олыларны хөрмәтләү, рәхмәт әйтә белүләренә игътибар ителгән. Табырга утыргач, ашка иң беренче булып өлкән кеше сузылган, һәр эшләгән эш өчен рәхмәт әйтүгә басым ясалган. Әтисенең үләр алдыннан Гомәрне чакырып, бирәчәкләрен түләргә әйтеп калдыруы, улын нәсел шәҗәрәсе белән таныштыруы − буыннар бәйләнешенең гүзәл үрнәге,

һөнәрле кешеләр күз алдында булганнар. Аларга һәркем хөрмәт белән караган. Яшьләр алардан үрнәк алганнар. Шулай ук укымышлы кешеләрне дә хөрмәт иткәннәр. Моны Гомәр үз җилкәсендә татый. Матур итеп хат яза белүе аның иптәшләре, авыл халкы арасында авторитеты күтәрелүгә китерә. Халык талантларга соклану белдергән. Ятим Әхмәтнең җырлавы һәркемне сокландырган, һәр авылның үз «артист»лары булган: скрипкада, гармунда уйнаганнар, моңлы итеп җырлаганнар, әкиятләр сөйләгәннәр, мәкаль-әйтемнәрне оста, урынлы кулланганнар.

Авыл халкы уңмаган, булдыксыз, юньсез кешеләрне яратмаган, аларга карата үзенең ризасызлыгын белдергән. Мәсәлән, акчасы күп дип, Әркәнәй карчыкны үтереп чыгу авыл халкында нәфрәт уяткан. Үзенә ошамаган, ямьсез эш кылучыларны, үлгәч, зиратка да күмдермәгән.

Тормыш авыр булса да, авыл халкы үз күңелен күтәрергә тырышкан. Гасырлардан килгән борынгы йолаларга тугры калган. Солдатка алынучы яшьләрне зурлап озатып калган, саубуллашу чәенә чакырган. Ә аракыга, эчүчеләргә карата авыл халкының үз карашы булган. Гомәрнең әтисе Бәшир абзый үз келәтендә кибет ачучыга аракы кертүне катгый тыйган.

Кешеләр арасында бер-берсенә мәрхәмәтле булу күренешләренә дә зур урын бирелгән. Әсәрдә егет-кызларның авыру Фазуллага карашы − шуның ачык мисалы. Васыять әйтүләр дә дулкынландыргыч итеп бирелә. Бәшир абзыйның Гомәргә, Мәрьямбикәнең сеңлесенә васыять әйтүләре калган кешеләргә читкә китәргә ирек бирми.

Әсәрдә гыйбрәт алырлык вакыйгалар, үрнәк алырлык геройлар бик күп. Алар барысы да кешенең рухын тәрбияләүгә, күңелен бизәүгә корылганнар.

## Текст 8

### М. Җәлилнең тоткынлыктагы кичерешләре

Муса Җәлил. Еш уйланам мин бу шәхес турында. Сугышка кадәрге тормышы хакында шактый беләм кебек: автобиографик язмасы да, истәлекләре дә, эзләнүләр дә, хатлары да бар. Ә менә тоткынлыктагы тормышын (әгәр «тормыш» дип әйтеп булса) ачык итеп күз алдына китерү кыенрак. Шигырьләре бу турыда сөйли, әлбәттә. Күз алдына да ул шулар аркылы килә. «Моабит дәфтәрләре» − шагыйрь тормышының елъязмасы («көньязмасы» дип әйтәсе килә). Шигырьләрен укыйм.

Тик булса иде ирек...

Әйе, кеше өчен иң кирәкле нәрсәгә мохтаҗ шагыйрь. Ул − «чәнечкеле тимерчыбык белән уратылган» төрмә ишекләрен ватып чыгарга омтыла: гасабилана, бәргәләнә, ашкына. Ләкин «таш капчык»тан чыгу юллары ябык диярлек. Бер юл бар барын... Әмма:

Алдый алмас мине түбән ләззәт,
Вак тормышның чуар пәрдәсе...
*(«Җырларым»)*

Богаулы шагыйрь берүзе генә түгел. Монда аңардан юату, дәртләндерү сүзен көтеп торучы милләттәшләре, дуслары, иҗатташлары. Аларның күз карашлары Шагыйрьгә төбәлгән. Шагыйрьнең дусларының иңбашларына кулын салып сүз әйтәсе бар.

Кайгырма, дус, яшьли үләбез дип...
*(«Дуска»)*

Киләчәк буыннар да үрнәк алырлык итеп яши дә, үлә дә белергә кирәк бит әле.

Әйтсен яшьләр: менә шулай яшәп,
Шулай үлсәң иде дөньяда!
*(«Дуска»)*

Кичерешләр... Шагыйрь биектә, иркендә очкан кошка карап моңая. Эх, аның да канатлары булса иде. Очар иде шагыйрь. Туган иленә, газиз сөйгәне, кадерле Чулпаны − йөрәк пәрәсе янына очар иде. Әкрен генә кызчыгының бишеген тирбәтер иде.

Шаян кызым син минем,
Таң йолдызым син минем...
*(«Кызыма»)*

Аннары сөйгәне янына килер иде. Килер иде дә, берничә сүз әйтер иде: «Үлгән дисәләр дә, алмаштырган илен дисәләр дә, арып егылган дисәләр дә – ышанма!» – дияр иде.

Синең сөю, серле тылсым булып,
Саклап килде йөргән юлымда.

*(«Сөеклемә»)*

Вакыт-вакыт шагыйрь үз-үзенә урын таба алмый: аның күңеле 9 баллы дулкынны хәтерләтә. Төрмәнең иң биек манарасына менеп, бөтен дөньяга кычкырасы килә.

Борыгыз муйнын комсыз карчыганың,
Кояш чыксын Алман җиренә.

*(«Алман илендә»)*

Шагыйрь дошманнарын «кеше» сүзе белән атый алмый. Алар – «хаин», «комсыз карчыга», «бурзай», «катыйль», «палач» исемнәренә генә лаек.

Кинәт батыр тынып кала. Чәнечкеле тимер рәшәткә аша төшкән саран гына кояш нурына карап уйлана ул.

Ах, ләкин онтылмый
Гомергә, гомергә
Электә татыган
Шатлыклар, рәхәтләр.

*(«Үткәндә кичергән»)*

Әмма бу – минутлык мизгел генә. Күңел әрни. Иреннәр «Кичер, илем!» сүзләрен кабатлый. Чөнки:

Данлы үлем белән күмәлмәдем
Бу тәнемне соңгы сулышта.

Шагыйрь оеп киткәндәй була. Нәрсә бу? Өнме, төшме?

Төштә миңа нәни кызым килде,
Чәчләремне сыйпап тарады.
– Ай-һай, әти, озак йөрдең,– диеп,
Күзләремә сөеп карады.

*(«Төрмәдә төш»)*

Төш икән шул. Төшнең дә әле ниндие! Яшәүнең, сөюнең, җир йөзенең, якын кешеңнең кадерен белергә өйрәтә торганы.

Әнә аның дуслары. Ә бусы – бельгияле дусты Андре Тиммерманс. Аңа бер бүләк ясыйсы иде. Тик тоткынның нинди бүләге булсын? Бар аның бүләге, бар. Ул бит шагыйрь.

Йөрәгемнең язгы гөлләр төсле
Җыры булсын сиңа бүләгем.

*(«Бүләгем»)*

Кичерешләр, кичерешләр... Үлем балтасын күтәреп яткандагы кичерешләр. Тетрәндергеч, шул ук вакытта сокландыргыч кичерешләр. Ниләр генә үтми шагыйрьнең күз алдыннан?!

Оренбург. Мостафа авылы. Олы җанлы, шигъри күңелле әнисе.

– Өч баламны очар кош итеп
Мин очырдым иркен далага...

*(«Ана бәйрәме»)*

Ана күңеле бары тик яхшы әйберләрне генә ишетергә тели. Аның улы да биргән антына тап төшермәс. Әнә бит ничек юата ул якыннарын.

Син үзең үк рәхмәт әйтмәссең бит,
Илгә җиңү алып кайтмасам.

*(«Сөеклемә»)*

Уйлар, уйлар... Коридорда аяк тавышлары. Бәлки, соңгы минутлар якынлашадыр. Яшәүдән инде өмете өзелгән шагыйрь тән яшәвенә түгел («Нәрсә ул тән?!»), рух яшәвенә ышана. Бу яшәүне аңа шигырьләре китерәчәк. «Көч» һәм «ялкын»ны аңа һәрвакыт шигырьләре бирде бит.

Җырым белән дусны иркәләдем,
Җырым белән җиңдем дошманны.

*(«Җырларым»)*

Шигырьләре шагыйрьне өметсезлектән, төшенкелектән коткарды, фашист тоткынлыгында

көрәшергә ярдәм итте. Дуслары күңеленә көч, рух өстәде, исемнәрен мәңгеләштерде.

Гомрем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңрар җыр булып.
*(«Җырларым»)*

Шундый кичерешләр белән гәүдәләнә шагыйрь Муса Җәлил минем алда.

## Текст 9

## Яраткан шигырем

1941 елның 22 июнендә немец-фашист илбасарлары безнең илебезгә басып керделәр. Халкыбыз, бердәм булып, дошманга каршы көрәшкә күтәрелде.

Япь-яшь егетләр, язучылар, туган җирләрен саклау өчен, фронтка киттеләр. Алар арасында Муса Җәлил дә бар иде.

Безнең илебездә М. Җәлилне белмәгән кеше юктыр. Муса Җәлил − Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты, бөек шагыйрь. Аның поэзиясен батырлык поэзиясе дип атарга мөмкин.

Муса Җәлил шигырьләрен мин яратып укыйм. Күптән түгел «Чулпанга» дигән шигырен укыдым. Мин үзем дә Чулпан бит! М. Җәлилнең дә кызы Чулпан исемле.

Шигырьнең беренче юлларында ук чагыштыру бар:

Чулпан йолдыз калыкты, нурланып.
Чулпан кызым шунда күз алдыма
Килеп басты, сузып кулларын.

Фронтка киткәндә кызы белән аерылышу бик авыр булгандыр әти кешегә:

Сизденмени синнән аерылганга
Әткәң күңеле шулай тулганын?..

Муса кызын бик яраткан булган:

Син янгансың икән йолдыз төсле,
Нурын сибеп гомрем таңында.
Әниең белән кызым − сез икегез
Тормышымның нуры идегез.

Ничек кенә авыр булса да, Җәлил сугышка китә:

Киттем, кызым, якты бәхтебезне
Бирмәс өчен фашист кулына...

Муса фашистлар белән көрәшә, туган илебезне, гаиләсен, баласын саклый:

Мин саклармын йөрәк каным белән
Илемне һәм сезне, аппагым!

Бу шигырьдә Җәлил кызы белән саубуллаша:

Хуш, аппагым, алсу таң атканда.

Үзенең җиңеп кайтуына ышана:

Мин кайтырмын сиңа, җиңү даным −
Автоматым булыр аркамда.

Киләчәктә яңа тормыш корып яшәвенә шатлана шагыйрь:

Без аталы-кызлы кавышырбыз,
Яшь аралаш көлеп, шатланып,
Һәм карарбыз илдә давылдан соң
Матурланып ал таң атканын.

Мине бу шигырь бик дулкынландырды. Муса Җәлил Чулпанны бик ярата. Ул кызына «аппагым», «йолдызым», «Чулпан кызым» дип эндәшә.

Ләкин шагыйрь сугыштан кайтмый. Җәлилне 25 августта Плетцензее төрмәсендә гильотинада үтерәләр. Чулпан кызы ятим кала.

## Текст 10

## Н. Фәттах. «Итил суы ака торур»

### Тарихлардай килгән хакыйкать

Без тарихта эзлебез.
*Г. Тукай.*

Язучы Н. Фәттахны татар әдәбиятында чын тарихи әсәр тудыручы дип атасак та ялгышмабыз. Аның үткәнне тулы итеп чагылдыру ягыннан «Итил суы ака торур» романы татар тарихи прозасының казанышы булып саналырга хаклы.

Романда Идел буе болгарларының тарихы чагылыш таба. Вакыйгаларда болгарлар дәүләтенең әле оешып кына килүе күрсәтелә. X гасырның иҗтимагый-тарихи, гаилә-көнкүреш үзенчәлекләре, сугыш вакыйгалары, хан-биләрнең тормышы кызыклы һәм мавыктыргыч итеп сурәтләнә. Ул чактагы тормыш рәвеше геройларның характерларында да күренә. Менә шундый бөтенлеккә ирешеп, Н. Фәттах ышандыргыч, кызыклы әсәр иҗат итә алган.

Романда чор өчен хас булган күренешләр сурәтләнә. Болгар дәүләте һөнәр, сәүдә, икътисад һәм мәдәният үзәге булган бай ил буларак гәүдәләнә. Акбүре ыруының Казаяклар һәм башка ырулар белән мөнәсәбәтләре тарихи фараз һәм легендаларга хас буяулар белән бирелә. Кабиләләр, ыруглар үзара аралашалар, сугышалар, һич көтелмәгән яктан килеп чыккан кан коюларга чик кую өчен берләшү кирәклеге, дәүләт булып оешу процессының һәр кеше тормышына йогынты ясавы кызыклы эпизодлар белән бирелә.

Романда төрки-татар дәүләтләренең беренче җитәкчеләреннән булган Алмыш хан образы сәнгатьчә яктыртыла. Ул – кыюлыгы, эшләгән эшләре белән халыкны ышандыра ала торган шәхес. Автор Алмыш ханның ислам байрагы астында бердәм дәүләт төзүен, үзара гел сугышып яшәгән ыру-кабиләләрне туплавын уңай күренеш буларак бәяли. Алмыш ханның ил-дәүләтен тагын да куәтлерәк итәсе килә, ә моның өчен аңа прогрессив дин кирәк була һәм ул аны ислам дине йөзендә күрә. Хан үзенә бик тә четерекле, әмма кирәкле заман таләбе булган бөек бурычны йөкли. Ул иске гореф-гадәтләр, йолалар белән яшәүнең мөмкин түгеллеген аңлый. Шул ук вакытта гасырлардан бирле килгән ата-баба гореф-гадәтләреннән котылуның җиңел булмавына төшенә.

Алмыш хакимнәргә хас табигый сыйфатлар белән гәүдәләнә. Үз ирекләре белән ата-баба диненнән, йоласыннан ваз кичәргә теләмәгән ыруларның кайсын куркыту, кайсыларына мал бирү юлы белән ул максатына ирешә. Хан үз теләкләре белән кушылган халыкларга дин иреген куя. Шул рәвешле, автор безгә «Милләтләрнең матур яшәү үрнәге ерак тарихта ук булган» дигән фикерне җиткерә. «Болгар йортның ханы бер генә булган кебек, аның Алласы да бер генә булырга тиеш! Барлык ил бер генә йолага – мөселман йоласына табынырга тиеш!» – ди ул.

Н. Фәттахның тарихи романында иҗади уйланган геройлар да шактый. Алар чор агышын тулыландырырга һәм әсәрне мавыктыргыч итәргә ярдәм итәләр. Бу геройлар төрле максатлардан чыгып яктыртылалар. Кайберләре, төп геройларга әверелеп, әсәрнең буеннан-буена үтә. Геройлар, тарихи хакыйкатьне гәүдәләндерү белән бергә, халык тормышындагы бизәкләрне һәм төсмерләрне ачып бирәләр. Аларның образларында шул чор кешеләренең әһәмиятле сыйфатлары, уй-хисләре тупланып бирелә.

Әсәрдә Тотыш образы вакыйгалар белән аерылмас мөнәсәбәттә тасвирлана. Аның язмышы романда күтәрелгән проблемаларны ачуда зур роль уйный. Романтик рухлы геройның, гадәттә, язмышы ачы фаҗига белән тулы була. Тотыш белән дә шулай. Алмыш ханга әсир (тотык) итеп алынгач, ул хан кызы Аппакка гашыйк була. Мәхәббәт өчен ул күп нәрсәләрне югалта, әмма үкенми. Хатыны Тәңкәне, улын, илен калдырып, Аппакны коткару өчен ул Хазар каганы биләмәләренә китә һәм шунда югала.

Әсәрдәге Торымтай, Бәкәч чәчән, Утамыш көтүче образлары аша; кол кешенең тирән фаҗигасе, психологиясе бирелә. Алар әсәрдә уңай яктан сурәтләнгәннәр. Бәкәч чәчән халык алдында Алмыш ханга «карак, угры» дип әйтүдән дә курыкмый. Ул Тотышның батырлыгына дан җырлый. Шуның өчен хан аның телен кистерә.

Н. Фәттахның геройлары заманга аваздаш. Алар бүгенге кешеләргә хас хисләр белән яналар, йомшаклыкларга биреләләр, бик үк дөрес булмаган эшләр эшлиләр. Аның геройлары яраталар, көнчел газаплары кичерәләр, ялгышалар.

Н. Фәттах үзенең персонажын бары тик уңай яки тискәре яктан гына күрсәтми. Әдипнең

максаты – шул чор тормышын тулырак күрсәтү. Шуңа күрә дә әсәрнең һәр элементыннан ерак тарих сулышы бөркелә. Әсәрдәге көч, күзәтүчәнлек нечкәлеге, нәфис тел, оста, индивидуаль төсмерләр белән ачылган характерлар һәм образлар бирелеше – болар барысы да алынган чорны җанландырырга, төп идеяне ачыкларга ярдәм итәләр.

Романның ахырында моңарчы таркау булган, бер-берсе белән сугышып яшәгән Идел, Чулман буендагы төрки кабиләләр бер байрак астына берләшә.

Н. Фәттахның «Итил суы ака торур» романы бүгенге көн кешеләренә тарихи хакыйкатьне ачарга, халкыбызның бөеклеген, аның тарихтагы урынын һәм ролен тоярга ярдәм итә.

## Текст 11

## А.Гыйләҗев. «Язгы кәрваннар»

### Сезнең тормыш – үзе батырлык

Халыкта «Үз язмышың үз кулыңда» дигән әйтем бар. Әйе, күп очракта бу шулай. Үз язмышыңны үзең төзисең, әйләнә-тирәдәге якыннарың, дусларың, җәмгыять тә синең язмышыңа күпмедер тәэсир итә. Ә инде бетен кешелекнең, җәмгыятьнең тоткан юлын, язмышын гел башка якка үзгәрткән зур тарихи вакыйгалар да булырга мөмкин. Безнең ил тарихында әнә шундый зур фаҗигаләрнең берсе Бөек Ватан сугышы булды һәм миллионлаган халыкның язмышын берничә минут эчендә үзгәртте дә куйды. Сугышның ачы хәсрәтле җиле һәр өйгә, һәр гаиләгә, һәр кешегә килеп сарылды.

Халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» әсәрендә дә Бөек Ватан сугышы чорында тылдагы халыкның язмышы, көнкүреше сурәтләнә. Сугышның рәхимсезлеге кешеләрне хәлсезләндергән, атлар күтәрәмгә калган, әмма әле сугышның кырыс юлларын үтеп бетерәсе бар. Алда – язгы чәчү. Чәчүлек кирәк. Иске-москы кигән, ярым ач, хәлсез, кайберләре авыру хәлендәге кешеләр, кәрван булып, кул чаналары тартып, алтмыш биш чакрым ераклыктагы элеваторга юнәлә. Яшәргә, тырышырга, фашизмны җиңәргә кирәк! Өмет чыгара аларны юлга. Алар бердәм, бер-берсенә искиткеч мәрхәмәтле, чыдам. Ашарларына да такы-токы гына. Бу язны түзсәләр, Җиңү киләчәк! Тырышырга, бирешмәскә кирәк!

Ләкин тормыш көтелмәгән яклары белән кешеләрне тагын бер кат сыный, Сабирәттәй юлда үлеп кала. Әгәр җитәкчеләр якындагы элеватордан чәчүлекне алып кайтырга рөхсәт бирсәләр, ул да исән калыр иде, башкаларга да җиңелрәк булыр иде бит!

Әсәрдәге вакыйгалар сугыш чорын үз башыннан кичергән һәр кеше өчен бик таныш һәм якын. Бүгенге көндә 90 яшен тутырып килүче дәү әниемнең дә яшьлегенең иң матур еллары сугыш вакытына туры килгән. Көзен егерме биш чакрым ераклыктагы районга икмәк ташысалар, язын, шуны ук күтәреп, кире алып кайтканнар. Зур елга аша чыкканда, күтәрәмле чабаталары су белән тула торган булган. Кайвакытта көненә икешәр дә барганнар алар. Урак урганда, көнгә 30 сутый норма булган, ә дәү әнием нормасын һәрвакыт арттырып үтәгән. Сугу машиналарын кул белән әйләндергәннәр, ашлыкны җилгә көрәк белән тотканнар, шулай чистартканнар.

Кыш көне үгез, сыер җигеп, Идел болыныннан печән ташыганнар. Лаеш районы Имәнкискә тирәсендә окоп казырга да, урман кисәргә дә туры килгән дәү әниемә. Черек бәрәңге, элмә кайрысы, алабута кушып пешерелгән күмәч, кычыткан ашы – болар сугыш чорының төп ризыклары булган.

Минем дәү әнием Мәгъмүрә уен-көлке, юморны бик ярата. Яшьтәше һәм ахирәте Шәрифҗамал әби белән очрашкач, аларның сөйләшеп сүзләре бетми. Көлә-көлә дә, елый-елый да искә ала алар сугыш елларын. Аларның күңелендә изгелек, яхшылык кына. Авыр сугыш елларында да шушы хисләр яшәргә көч биргән, өмет, теләк һәм тырышлык белән яшәп, алар Җиңү көнен якынайтканнар. Тылдагы һәр кешенең хезмәте – ул зур батырлык.

Күренекле язучыбыз Аяз Гыйләҗев «Язгы кәрваннар» повестенда тылдагы кешеләрнең күңел матурлыкларын, олы җанлы, киң күңелле булуларын, үзләренең хәле хәл булса да, башкалар турында кайгыртып яшәргә омтылуларын Сабирәттәй, Хәкимҗан абый, Сәрвәр апа, Габбас абыйлар аша сурәтләсә, сугыш та җиңә алмаган яшь җаннарның күңел матурлыгын, мәхәббәтнең, дуслыкның олылыгын Ибраһим, Әдилә, Дамир образлары аркылы безгә җиткерә. Өмет, теләк көчле

булганда, яшәү дә матур булачак. Аларның һәркайсының тормышы − үзенә күрә батырлык.

### Текст 12

### Һәр кешенең гомере − язылмаган китап

Без сугыш чоры балалары түгел. 36 яшендә, биш баласын калдырып, сугышка чыгып китеп, ярты Европаны узган, Җиңү шатлыгын күрү бәхетенә ирешкән һәм исән-имин туган якларына әйләнеп кайтып, тормыш корган бабамның төпчек улы Рәйдамның кызы − Энҗе мин.

...Сугыш ул − Сәхиб бабамның сөйләгәннәре дә, аның сугышта алган яралардан төннәр буе сызланып чыгуы да. Аның иңбашына кереп урнашкан дошман ядрәсе үләренә ике-өч ай кала үзенең барлыгын бик еш сиздерде: бабам ядрәнең урыныннан кузгалуы, сызлануы турында гел әйтә иде. Сугыш гарасатларының бөтен фаҗигасен үз күзләре белән күргән бабам да якты дөньяда юк инде.

...Сугыш ул − шкаф тартмасында 60 елдан артык саклана торган, ялтырап яткан бик күптөрле орден-медальләр дә. Аларның да кешеләрнеке кебек үз тарихы, үз язмышы. Бабамның ул бүләкләре безнең гаиләдә кадерле истәлек итеп саклана, әмма аларның һәркайсыннан сагыш, ачы күз яшьләре тамган кебек тоела миңа.

Минем Сәхиб бабам күбрәк утырып йоклый иде. Кечерәк вакытта минем дә, уеннан соң арып, аның янына утырып йокыга киткән чакларым булды. Бездән: «Сугышта бергә булдыгызмы әллә?» − дип көләләр иде. Үсә төшкәч кенә аңладым: алар төнлә дә, көндез дә сугышчан әзерлектә торганнар, шуңа утырып йокларга гадәтләнгәннәр икән. Әтиләребезгә, безгә, балаларыбызга утырып йокларга насыйп итмәсен иде, Ходаем!

Һәр кешенең гомере − язылмаган китап, диләр. Кайгы кайгыга охшамаган кебек, язмышлар да бер-берсенә охшамый. Бабамнар фронтка барганда, эшелоннарын немец самолетлары бомбага тота. Шунда бик күп сугышчы һәлак була. Исән калганнары 200 километрдан артык юлны коеп яуган яңгыр астында җәяү үтәләр. Великие Лукидан ерак түгел бер авыл янында окоп казып урнашалар.

Фронтта сугыш кирәк-яраклары, күп вакытта азык-төлек тә җитешми. Алар, җилкәләренә күтәреп, снаряд та ташыйлар, типсә тимер өзәрдәй ир-егетләр ачлыктан да интегәләр, суыктан һәм үз вакытында беренче ярдәм күрсәтелмәүдән дә газап чигәләр. Аларның ул вакыттагы хәлләрен күз алдына да китерүе кыен. Бабам, ике тапкыр яраланып, госпитальдә ятып чыга. Шуннан соң инде сәламәтлеге какшаган бабамны пешекче итеп куялар. Аларның кыр кухнялары сугыш сызыгыннан берничә йөз метр гына артта бара. «Үлем турында уйларга вакыт булмады»,− дия иде бабам. Алар батырларча көрәшкәннәр, куркусыз булганнар. Ә шул ук вакытта гомере буе авылда яшәргә, икмәк үстерергә хыялланган бабам кебек асыл ир-егетләр аз үлмәгән ул сугышта. Барып баш ияргә каберләре дә юк бит мәрхүмнәрнең.

Юл чатында каберләр күп,
Гөлләргә уралганнар.
Ә кайда соң сезнең кабер,
Хәбәрсез югалганнар?!

...Сугыш ул − өч баласы белән тол калган Һидая, Гөлзифа әбиләр, ирләре белән берничә ай да яшәргә өлгерми калган башка әбиләр дә. Алар гомер буе ирләрен көтеп яшәделәр.

1941 ел балалары да шактый икән авылыбызда. Күбесе − әтиләре сугышка китәч туган балалар. Бер тапкыр да «әти» дип әйтә алмыйча, әтисез үскән буын. Аларның да әтиле балалар шикелле: «Әтигә әйтәм мин сине», − дип үртәшәсе килгәндер...

...Сугыш ул − унике яшеннән әтисез калып, тылдагы бөтен авыр эшне үз җилкәсендә татыган, әниемнең әтисе Мөхәммәт бабам язмышы да. Әтисе Хаҗип сугышка киткәндә, бабама: «Сеңелләреңне, энеңне карарга әниеңә булыш», − дип әйтеп калдыра. Мөхәммәт бабамның эшләмәгән эше калмый: үгез җигеп сука сукалый, урак ура, көлтә ташый, урман кисә, төннәрен чабата үрә. Әтисе булганда алган өч класс белеме белән кала ул. Шуңадыр инде, гомере буе укуның кадерен белергә өндәп яшәде. Аның күргән газаплары да эзсез узмаган: саулыгын югалткан. Шушы сугыш афәте булмаса, унике яшеннән тормыш аның үз өстенә калыр идеме соң?

... Бабам истәлеге булып, Олы Әшнәк авылындагы бакча башында ул утырткан зирек

агачлары әкрен генә леперди. Әйтерсең лә бабамның изге теләкләрен җиткерәләр:

Тәлгәш-тәлгәш зирек алкалары
Нәрсә әйтергә телиләр икән?
− Тыныч илләрдә яшәгез,
Сугыш күрмәгез, −

диләр микән?

...Сугыш ул − өч яшендә ятим калган Зәйтүнә әбиемнең ачы язмышы да. Аңа өч яшь булганда, әнисе үлгән була, озакламый әтисеннән дә хәбәр өзелә: кара мөһерле хат кына килә.

...Сугыш, сугыш... Кемнәрнең язмышына кагылмаган да, кемнәрнең башларына кайгы, күз яше, хәсрәт китермәгән ул. Кешелек дөньясы, сугышлардан ачы сабак алып, җир йөзендә мәңге тынычлык, бәхет өчен көрәшергә тиеш.

Сугышлар беркайчан да булмасын иде. Гөрләп туйлар узсын, сабыйлар тусын, барысы да әтиле-әниле үссеннәр! Җирдә матурлык яшәсен! Бары матурлык кына дөньяны афәттән саклый.

## Текст 13

### Сажидә Сөляйманова − минем яраткан шагыйрәм

Бик шатландым синен өчен, Сажидә.
Күңелне җилкендерә торган шигырьләр дә,
уйландыра-моңландыра торганнары да бар.
Бушка әйтелгән сүз юк, һәр сүзнең төбендә
йөрәк, акыл ята.

*М. Кәрим хатыннан.*

Мин шигырьләр яратам. Яраткан шагыйрьләрем дә бар. Шагыйрьләр арасында мине аеруча җәлеп иткәне − Сажидә Сөләйманова. Бер очрашуда шагыйрь Х. Туфан Сажидә исемен ишеткәч: «Ай, матур исем! Сажидә − сәҗдә кылучы, кешеләрне, яшәешне олылаучы хатын-кыз...» − ди. Әйтерсең шушы сүзләре белән олы шагыйрь С. Сөләйманованың киләчәген пәйгамбәрләрчә дөрес билгели.

Чынлап та, шагыйрь фаразлаганча, С. Сөләйманова шигырьләре аша тормышка, аның матурлыгына сәҗдә кыла. Үләр алдыннан язган «Тормыш, исәнме!» шигырендә ул яшәүнең чиксез матурлыгын тоеп:

Сахраларга чыксаң, җырлап туймас
Җыр икәнсең, тормыш, исәнме! −

дип яза.

С. Сөләйманова, башка шагыйрьләр кебек, үзенең кечкенәдән шигырь язуы турында әйтми, әмма көндәлегендә берничә юл бар.

Ләкин биографиясеннән аның шигъри җанлы, романтик рухлы кыз икәне ачыклана. Аның поэзия мәйданына аяк басуы турында ире Әдип Маликов болай дип яза: «Сажидә поэзия мәйданына соңлабрак, хисләре тулышып өлгергәч кенә аяк басты. Үзе алдан сиземләгәнчә, җыр булып ташып чыкты ул».

С. Сөләйманова тумышы белән Башкортстаннан. Үзенең бер шигырендә шагыйрә туган җире белән горурланып:

Җыр булып ташып чыгармын
Чыгышым Агыйделдән, −

дип яза.

Шагыйрәнең йөрәге кешеләргә ачык. Шуңа күрә аның шигырьләре һәркемне үзенә тарта. Уйландыра да, моңландыра да бу шигырьләр. Шигърияттә аның үз юлы бар. «Бәхетне үзем табам» дигән юллар авторның беркемне дә кабатламавы, беркемгә дә иярмәве турында сөйли. Аның геройлары − эшчеләр, нефтьчеләр, әдәбият-сәнгать әһелләре, туган ягының гади кешеләре. Ул аларга хезмәт итә, һәрчак алар арасында. Шагыйрьнең урыны сафлар алдында булырга тиеш.

Таянычым − шундый эшче халык.

Без походта, тормыш, яңгырат маршың!
Кояштан таҗ кояр алтын куллы
сафлар алып чыгам,
мин – маршал!

*(«Укытучы»)*

С. Сөләймsecurityанованың беренче шигырьләре район газетасында дөнья күрә. Ул үзенең туган ягын да онытмый. Башкортстанның «Кызыл таң» газетасына да җибәрә. Шигъри күзәтүдә аның турында: «Әлмәт шәһәреннән С. Сөләйманованың шигырьләре күңелдә аеруча өмет тудыра», – дигән сүзләр языла.

Шулай итеп С. Сөләйманова матбугатта басылган беренче шигырьләре белән үк шигърият дөньясында үз урынын алуга иреште. Шагыйрә моны үзе дә сизә, шуңа сөенә.

Замандашлар,
ярый сезнең белән
бергә туры килгән гомерләр!

*(«Шуңа сөенәм»)*

С. Сөләйманова поэзияне гашыйклар эше дип саный. Ләкин бу кешегә карата булган сөю генә түгел, гомумән, дөньяга, һәр җан иясенә, табигатькә, тормышка мәхәббәт.

Сөюмени, бәхет каршына
Канатланып күңелең очмаса?

*(«Сөюмени»)*

Шагыйрә фикеренчә, иҗат кешесе һәрнәрсәгә, һәр каршылыкка әзер булырга тиеш.

Күк барында —
җирдә уклар да бар, –
тыныч яшимени шагыйрьләр!

*(«Кызыл каурыйлар»)*

Мине шагыйрәнең шигъри теле сокландыра. Аның бу осталыгын өлкән язучылар да билгеләп үтә. Теленең төзеклегенә, матурлыгына Г. Бәширов, М. Кәрим, С. Хәкимнәр дә игътибар итәләр.

Гөл серләрен тыңлар идем,
чәчәк атса бер гөлем.
Таңда торып, сандугачтан
өйрәнимме җыр телен?

*(«Ач, шигърият, серләреңне»)*

Җырлап торган моңлы да, җитди дә, тирән дә, матур да шигырьләре белән менә шундый «җыр телле» шагыйрә булып кереп калды ул минем күңелемә. С. Сөләйманова шигырьләрен укып, мин шуны аңладым: Х. Туфан әйткәнчә, «чын шагыйрь юлы иң катлаулы, иң авыр, ләкин иң гүзәл, олы, бай, бәхетле юл ул...»

## Текст 14

### Ач, шигърият, серләреңне...

Шигърият үз серләрен һәркемгә дә ачмый...
*Н. Юзиев.*

Саҗидә Сөләйманова дип әйтүгә, күңелдә «Урсал тауда...» җыры тибрәнә башлый:

Үтә айлар, көтә
Зәйләр, суларында йөзәлмим...
Урсал тауга карлар яуган,
барам инде, түзәлмим...

Шагыйрә туган ягына әнә шулай ашкына, аңа мәдхия җырлый. Синең дә шунда тизрәк барасың, Урсал тауны күрәсең килә башлый.

Кешедә булган кешелеклелек сыйфатлары, мәрхәмәтлелек хисләре дә автор өчен «туган җир, туган туфрак» төшенчәләреннән башлана.

Туган җир ул кеше күңеленә
Ана сөте белән салына, –

ди ул «Туган җирем, эчкән суым!» шигырендә. «Туган җир» һәм «ана сөте» – кеше өчен бәяләп бетергесез кыйммәтләр. Алар алдында кем үз бурычын түләп бетерә ала? Бары тик иле өчен, халкы өчен, яшәү өчен җаннарын фида иткәннәр генәдер, мөгаен. Әсәрдә автор туган якның кадерен дә, аның кеше өчен үтә мөһимлеген дә әйтергә тели. Туган җир, туган як кеше күңеленә моң сала, аны канатлы, илаһи итә, яшәүгә көч бирә, шуңа ул аның алдында үзен бурычлы тоя:

Тәпи баскан җирем, эчкән суым
кара, акмы, ачы, татлымы –
бөтен гомерем белән түли алмам
шушы җирдә яшәү хакымны.

*(«Туган җирем, эчкән суым!»)*

С. Сөләйманова шигырьләрендә эчке моң, ниндидер үзәк өзгеч сагыш бар. Бер үк вакытта ул сине илаһи ераклыкка, биеклеккә алып китә дә, шул ук вакытта җирдәге чынбарлыкка кайтарып та куя. «Кеше барыбер кошлар нәселеннән!», «Кеше» исемле шигырьләрендә әнә шул хисләрне тоясың. Кешене лачыннар биеклегенә күтәрә ул, горур булырга чакыра. Кеше барлык кыйммәтләрдән өстен, дигән фәлсәфи фикерне үткәрә. Шулай булмаса, дөньяның бөтен бәла-казалары адәм баласы өстенә төшәр идеме соң?

Аның мәхәббәткә багышланган шигырьләрендә кеше күңелен дулкынландырырлык сер бар. Алар синең күңелеңне җилкендерә дә, уйландыра да, моңландыра да. Әмма бушка әйтелгән сүз юк, һәр сүзнең төбендә изгелек теләп торган хатын-кыз йөрәгенең саф хисләре ята. «Җитәкләшеп икәү бара, эзләренә ак кар ява», – ди ул «Этюд» шигырендә. Ике яшьнең самими хисләрен күреп, аларның киләчәге өчен ихлас борчылу да бар шагыйрә күңелендә. Ялгышмасলармы? Үткәннәргә кайтып булмаячак бит. Һәм авторыбыз теләк тели:

Эзләренә кер кунмасын,
җил тимәсен,
суынмасын.

С. Сөләймановaның лирик герое – үтә зәвыклы, сизгер, нечкә күңелле. Лирик герое белән автор образы аның иҗатында шактый якын, һәм еш кына аларны бер-берсеннән аера да алмыйсың. Әйләнә-тирәне, дөньяны, вакыйгаларны ул үзенчә кабул итә, аларга фәлсәфи якын килә, нечкә лирика һәм тирән фикер, аз сүз белән әйтеп бирә ала. Шагыйрәнең сүз куәте көчле.

Мин иншамны әдәбият галиме Нил Юзиевнын С. Сөләйманова иҗатына биргән бәяләмәсе белән тәмамларга телим. Ул болай ди: «Шигърият үз серләрен һәркемгә дә ачмый... Шигырь язучылар арасыннан шигърият бик нык сайлый: күңел биографиясе һәм әйтер сүзе булганнарын, тормыш агышына-моңына сизгер күңелләләрен, шигъри күрү-ишетүгә ия булганнарын... Шагыйрь ни дәрәҗәдә поэзиягә ышанса, күңелен курыкмыйча ачса, шигърият тә серләрен иркенрәк өләшә...»

Әйе, Саҗидә Сөләйманова – шигърият серләрен ачкан олы Шагыйрә!

**Текст 15**

**Иң татлы тел – туган тел,**
**Анам сөйләп торган тел**

И туган тел, и матур тел!
Әткәм-әнкәмнең теле.
Дөньяда күп нәрсә белдем,
Син туган тел аркылы.

*Г. Тукай.*

Мин – авыл баласы. Кечкенәдән җырлы, моңлы, гаҗәеп гүзәл табигатьле авылда үсеп киләм. Авылымның челтерәп аккан чишмәләре, бормалы инешләре, шаулап торган серле урманнары, игеннәргә бай басу-кырлары, газиз кояшның беренче нурларын каршылаучы мәчет манарасы – болар минем йөрәгем түрендә. Чөнки мине әти-әнием, укытучыларым туган якның матурлыгын

аңлый белүче, туган телен яратучы, аңа гашыйк булган кеше итеп тәрбияләргә тырышалар. Үз халкымның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре каныма сеңә. Бигрәк тә, киләчәктә татар теле һәм аның үсеше өчен зур эшләр эшлисем килә.

Ана һәм Туган тел! Мәңге аерылгысыз, изге төшенчәләр. Мин үзем «ана сөте белән» дигәнне дә «ана теле» дип ишетәм. Мәгълүм мәкальне дә: «Ана теле белән кермәсә, башка тел белән кермәс», − дип аңлап була. Күрче, татарда бит туган тел дип тә, ана теле дип тә әйтелә. Кешегә нәселнең, халкының асыл сыйфатларын да иң әүвәл тел тәме, тел кодрәте ярдәмендә ана бирә. Бала табу вазифасын беркемгә дә тапшыра алмаган кебек, баласына тел ачкычы бирү бурычын да ана беркемгә дә ышанып тапшыра алмый.

Әйе, бу эштә эти дә, әби-бабай да, туганнар да, балалар бакчасы да, мәктәп тә катнаша, алар да җаваплы, әмма бала күңеленә тел орлыгы чәчү − бары тик ана җаваплылыгында. Мин үзем − газиз телемне әниемнән мирас итеп алган иң бәхетле кешеләрнең берсе. Югыйсә, кайберәүләр, шактый озын гомер кичереп тә, мондый бәхеткә ирешә алмаганнар, андыйларның фаҗигасен күп ишеткәнем бар.

Гәрчә, бу соңгы елларда ана телебездә уңай якка үзгәрешләр дә булды. Тәрбия эше белән бәйле зыялыларның, аналарның, матбугатның, Туфан Миңнуллин кебек депутатларыбызның тырышлыгы бушка китмәде: татар теле башта Татарстанның Дәүләт суверенлыгы турында декларациядә, аннары Татарстан Республикасы Конституциясендә дәүләт теле буларак рәсмиләштерелде. Иң мөһиме: татар кешесендә ана теле өчен горурлык хисе, аның язмышына карата өмет тойгысы бөреләнеп, шул хисне ачыктан-ачык әйтүдән курыкмау, оялмау үсә башлады. Ә бу адәм баласының иң изге хисе − туган телгә гамьле, хөрмәтле булганда гына кеше үз иленең, төбәгенең, гаиләсенең шәҗәрәсен, тарихын аңлый ала; халкыңны, тарихыңны белүдән башкалар теленә хөрмәт белән карау фикере тәрбияләнә.

«Тел − ананың зур бүләге». Мин әни биргән бүләккә бик сөенәм, аның белән горурланам. Юкка гына шагыйрь Сибгат Хәким дә язмышыннан: «...ирекле ит, туган телем белән бәхетле ит, бүтән йөдәтмәм...» − дип үтенмәгәндер. Бишек җырларын тыңлап үскән кеше генә үз ана телен яхшы белә аладыр ул. Мин үзем дә шундый бәхеткә ирешкән бала.

Миңа әнием бишек җырлары урынына күбрәк Г. Тукай сүзләренә язылган «Туган тел» җырын җырлаган. 3-4 яшькә җиткәндә, бу җырны үзем дә җырлый идем инде. Аны бит миңа әнием өйрәткән, өйрәтеп кенә калмаган, каныма сеңдергән, бу кан бөтен тәнем буйлап хәрәкәт иткән. Шулай булмаса, туган телемне − ана телемне бу кадәр яратыр идемме соң?!

Әнием җырлар җырласа, этием әкиятләр сөйли иде, ул аларның күбесен үзе уйлап чыгара. Җилле-давыллы кичләрдә бездә еш кына ут бетә. Өйдә ут беткән кич безнең өчен әкиятләр кичәсенә әйләнә. Әтиебез 3-4 сәгать буе әкият сөйли иде. Сабый өчен эти-әнисе канаты астында үз телендә әкият тыңлаудан да зур бәхет юктыр ул.

Бу дөньяда бер генә баланың да бер генә анага да шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов сүзләре белән:

Тел, әдәп, әхлак дигәнне өйрәтмәгән хатын,
«Ана» дип аталырга бармы синең хакың?! −

дип әйтергә теле бармасын, җае чыкмасын иде. И-и-и, аналар, тәрбияләп үстергән балагызга сез чын йөрәктән Сажидә Сөләйманова сүзләре белән:

Йөрәк каным белән Ил бирдем дә,
Күкрәк сөтем белән Тел бирдем,
Саклый алсаң − мәңгелек фатихам.
Җуйсаң, сатсаң − күкрәк сөтем хәрам!.. −

дип әйтә алсагыз иде, ә без, балалар, сезгә Зыя Ярмәки сүзләре белән болай җавап бирә алсак иде:

Күңелемә алтын кебек сүзләр тезеп киткән әни,
Мин сөйләрмен, әнкәем, илгә синең ул сүзләрне.
И, миңа тойгы сөйләрлек тел биреп киткән әни.

Әтием, әнием − минем өчен иң кадерле кешеләр. Тигез канат, тату гаиләдә үсүем белән дә мин чиксез бәхетлемен. Аларга һәм туган телемә рәхмәтемне үзем иҗат иткән шигъри юллар аша җиткерәсем килә:

Бар җиһанга эндәшәсем килә:
− Мин бәхетле, ап-ак кышым бар.

Үз телендә генә сайрап торган
Күңелемдә бәхет кошым бар.
Мин бәхетле, әбкәм сине тапкан
Һәр ел саен килгән язым бар.
Гомер һәм тел бүләк иткән әнкәм,
Җаным тулы сиңа назым бар.
Мин бәхетле, җиргә әткәм туган,
Муллыкка күмелгән көзем бар.
Туган телдә җырлап яшәүче
«Ләкләк» алып килгән үзем бар.

## Текст 16

## Г.Тукай. «Исемдә калганнар»

### Асрарга бала бирәм, кем ала?

> Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!
> Азрак үстерде сыйпап тик маңгаемнан милләтем.
>
> *Г. Тукай. «Дошманнар».*

Габдулла Тукай «Исемдә калганнар» әсәрендә үз башыннан кичергән хәлләрне укучы белән уртаклаша, ятим бала өстенә төшкән авырлыкларны ярым ярату, ярым шаярту белән сыкранмыйча яза.

Габдулла 5 айлык чагыннан − әтисез, ә дүрт яшьләр тирәсендә әнисез дә кала.

Шуңа үзен белә башлавы ятимлек, кулдан кулга йөрү, ачлы-туклы яшәү, «артык кашык» булу һәм усал карашлар белән исендә калган.

...Өчиледәге хәле бик авыр була аның. Бердән, ачлык, икенчедән, «артык кашык», «килмешәк» сыйфатында кимсетелеп яшәү. Шуның өстенә әллә нинди чирләр ябырыла аңа. Тәмам зәгыйфьләнә. Менә шул вакытта бабасының үтенүе һәм үги әбисенең «тырышлыгы» белән ул Казанга килә. «Ямщик, − дип яза шагыйрь, − Казанга килеп җиткәч (безнең авыл Казаннан 60 чакрым), Печән базарында: «Асрарга бала бирәм, кем ала?» − дип кычкырып йөргәндә, халык арасыннан бер кеше чыгып, мине ямщиктан алган».

Бу вакытта нәни Габдулла ниләр кичерде икән? Бәлки, әле ул үз хәленең асылын да аңлап бетермәгәндер, шуңа да ямщикның сүзләренә артык игътибар да итмәгәндер?! Ул беренче тапкыр күргән биек йортлар, ат җигелгән вагоннар аның үз хәлен оныттыргандыр. Зур булып ачылган күзләре белән мыж килеп торучы халыкны, җирдә, ларeклардагы исәпсез-хисапсыз әйберләрне, ашамлыкларны күзәтә...

Габдулланы һөнәрче Мөхәммәтвәли белән Газизә асрамага алалар. Икесе дә эш кешеләре булганлыктан, монда Габдулланың тамагы тук, өсте бөтен була. Күпмедер ата-ана назын да татыган. Ләкин Газизә вакыт-вакыт сабыйның күңелен аңлап җиткермәгәнме, әллә бераз саранлык булганмы: «Кайчакта әни белән Ташаяк базарына барып, андагы уенчык базарларына кызыгып вә самокатларда шатланып-шатланып агач атларга атланган малайларны карап, көнләшеп тора идем», − дип яза ул үзе соңыннан. Габдулла, шәһәрнең ялтыравыклы яклары белән бергә, бистә ярлыларының тормышын да үз күзләре белән күреп, акны карадан аера башлый.

Габдулланың «кара бәхете» үзеннән калмый. Ике еллап торганнан соң, аның әти-әниләре икесе дә авырый башлыйлар. «Без үлсәк, бу бала кем кулына кала, ичмасам, авылына кайтарыйк»,− дип, аны кире Өчилегә озаталар.

«Асрарга бала бирәм, кем ала?» дип, базарда «сатылуын» бала күңеле онытa алмаса да, Казан Габдулла күңелендә матур истәлек калдырган.

*Бирем. М. Казаковның «Үксез бала» рәсемендә Габдулланың күз карашын характерлап сөйләгез. Сабыйның күзләрендә ниләр күрәсез? Рәсем сездә нинди тәэсир калдырды?*

М. Казаковның «Үксез бала» рәсемендәге Габдуллага дүрт-биш яшьләр чамасы. Сабыйның, нәрсәнедер аңларга тырышып, томырылып карап торуы үзәк өзгеч моң, тирән сагыш белән өретелгән. Бу бала бик күзәтүчән, олыларча уйларга сәләтле, фикерләүгә ия. Автор баланың шушы халәтен шулкадәр табигый, тормышчан итеп сурәтләгән ки, үзеңне дә шул бала янында итеп сизә башлыйсың, аны кочагыңа алып иркәлисе, назлыйсы килә...

Алдында − катык, ярып пешерелгән бәрәңге, кара ипи, агач кашык, чи бәрәңгедән ясалган уенчык.

Сабыйның игътибарын нindидер көтелмәгән хәл җәлеп иткән. Кыш фасылы булса кирәк, чөнки Габдулланың аягында йон оекбаш. Авыл баласы җәй көне яланаяк йөрергә ярата бит. Элек җылы абзарлар булмаган, шуңа күрә хуҗабикәләр сыерны өйгә алып кереп сауганнар. Хәтта яшь бәрәннәр, бозаулар өйдә торган. Өйгә алып кергән сыерны савучы әнисенең хәрәкәтләрен күзәтәме? Әллә яңа гына йомыш белән ишектән кергән күршегә карыймы Габдулла? Һәрхәлдә, бала

игътибарын җәлеп итәрлек вакыйга бар ул караган якта.

Сабый алдына куелган кайнар бәрәңгенең суынганын сабыр гына көтеп утыра. Менә-менә ул хәзер ашый башлар кебек. Өй җылы, чиста; бик пөхтә итеп сәкегә урын-җир җыеп куелган. Тынычлык, туклык сизелә. Кыш булуына карамастан, тәрәзә төбендә гөлләр чәчәк атып утыра. Тәрәзәдән төшкән яктылык Габдулланың йөзен яктырта. Төсләр, буяулар якты, ачык.

Алда ятимлек, фәкыйрьлек җәфалары күрәчәк даһиның бәхетле сабый чагын сурәтли рәссам.

Әсәр бик җанлы, тормышчан, мәгънәле. Тукайның җитди, уйчан, сагышлы күз карашы күңелдә озак саклана. Бу инде рәссам М. Казаковның таланты турында сөйли.

## Текст 17

## Үзем турында

Мин, Баязитова Минзилә Нәҗип кызы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы Балыклы Чүкәй авылында 1993 елның 15 мартында хезмәткәр гаиләсендә туганмын.

2000 елның 1 сентябрендә Балыклы Чүкәй урта мәктәбенең 1 нче сыйныфына укырга кердем. 3 нче сыйныфта укыганда, Татарстан варислары сафына кабул ителдем.

Бүгенге көндә шул ук мәктәпнең 5 нче сыйныфында укуымны дәвам итәм. Әдәбият, тарих фәннәре белән кызыксынам. Сыйныфта үзешчән сәнгать эшчәнлегенә җитәкчелек итәм. «Оста куллар» түгәрәгенә йөреп, тегәргә, чигәргә өйрәнәм. Буш вакытымда әдәби китаплар укырга, музыка тыңларга яратам.

Әтием Баязитов Нәҗип Шамил улы − Балыклы Чүкәй муниципаль берлеге рәисе, ә әнием Баязитова Нажия Харис кызы урта мәктәптә китапханәче булып эшли. Энем Нияз 1 нче сыйныфта укый.

17.10.2020ел Баязитова.

## Текст 18
## Сара Садыйкова

1. Татар музыка сәнгатендә Сара Садыйкова исеме—уникаль исем. Татар музыка сәнгатенең энҗесе ул. Уйлап кына кара, бер шәхес өч төрле сәнгать осталыгын үзенә туплаган: беренчедән, ул Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының Т. Гыйззәт, К. Тинчурин, С. Сәйдәшевләр белән бергә татар сәхнә корифейларының данлыклы музыкаль спектакльләрендә образлар иҗат иткән драма артисткасы. Икенчедән, Татар опера һәм балет театрының пәрдәсен ачып җибәреп, беренче милли операларда онытылмас образлар тудырган опера солисткасы (1925 елны беренче татар операсы "Сания" махсус аның тавышына языла). Өченчедән, беренче татар хатын-кыз композиторы, соңгы сулышына кадәр гүзәл җырларын язып, халкына бүләк иткән композитор.

*(С. Садыйкованын кызы Әлфия Айдарская истәлегеннән)*

Бирем: Түбәндә күренекле татар композиторы, Габдулла Тукай исемендәге бүләк лауреаты Сара Садыйкова турындагы истәлекләрдән өзекләр бирелә. Игътибар белән укыгыз, тыныш билгеләрен аңлатыгыз. Сара Садыйкова турында материаллар туплап, өйдә "Татарстан сандугачы" дигән темага яки композиторның үзегез бик яраткан бер җыры турында сочинение языгыз.

## Тексты для русскоязычной группы

### Текст 1

### Как быть хорошим

Нет людей неталантливых и некрасивых. Однако не каждый из нас умеет находить свой талант. Точно так же не каждый может преподнести себя в наиболее выгодном свете.

Однако этому можно научиться. Речь в данном случае идет о том, как раскрыть свои духовные, душевные достоинства. Прежде всего – перед собою, для себя. Для этого, оказывается, надо всего лишь выполнять некоторые обязанности по отношению к себе самому и своим близким. Например, исправлять недостатки своего характера, избегать постоянной праздности, привыкать к труду, стараться довольствоваться малым, не делать людям зла – даже врагам, не оскорблять ближних ни словами, ни действиями и ряд других обязанностей. Тогда любой назовет вас хорошим, воспитанным человеком.

### Текст 2

### Татарстан

Площадь территории Татарстана – 68 тысяч кв.км. Население – 3 млн. 700 тысяч человек. В республике проживают представители 107 национальностей. В составе республики Татарстан считается 43 административных района, 19 городов, 22 поселка городского типа и 829 сел.

На сегодняшний день Татарстан составил двусторонние соглошение с Российской Федерацией, Украиной, Белоруссией, Молдовией, Узбекистаном, Туркменстаном, и многими областями России.

В республику вводится природный газ, металл, сельскохозяйственные машины, минеральные удобрения, оконные стекло, материалы из дерева, строительная и дорожная техника, медицинская техника.

Из республики в другие государства вывозятся грузовые автомобили, часы, холодильники, автомобильные шины, меховые изделия, лекарства, измерительные приборы.

Татарстан подписал двусторонние договора со многими странами мира. В других странах у нас имеются полномочные представители. Они доводят информацию о Татарстане жителям иностранных государств. Для Татарстана в равной степени важны отношения с Западом и Востоком.

Внешняя политика для Республики – это не только поднятие авторитета Татарстана во всем мире. Это значит – и поиск рынка для торговли, и приобретение знаний. Без этого невозможно производство качественных товаров.

### Текст 3

### Национальная татарская одежда

Национальный татарский костюм прошел длинный путь исторического развития. Костюм – наиболее яркий «индикатор» национальной принадлежности, воплощение понятия об идеальном образе представителя своей нации. Сливаясь с физическим обликом, он рассказывает об индивидуальных особенностях человека, его возрасте, социальном положении, характере, эстетических вкусах. В разные периоды истории в костюме сплетались моральные нормы и историческая память народа с естественным стремлением человека к новизне и совершенству.

Татарский костюм представляет собой уникальную систему народного художественного творчества, включавшую в себя изготовление тканей, сложных и богато орнаментированных головных уборов, производство различных видов обуви, высокохудожественных ювелирных украшений. Все элементы системы выступали согласованно, сочетаясь друг с другом по форме, цвету, материалу изготовления, образуя единый сти¬левой ансамбль.

Верхняя одежда татар была распашной со сплошной приталенной спинкой. Поверх рубахи надевали безрукавный (или с коротким рукавом) камзол. Женские камзолы шили из цветного, чаще однотонного бархата и украшали по бортам и низу позументной тесьмой, мехом. Поверх камзола мужчины носили длинный просторный халат (жилэн) с небольшим шалевым воротником. Его шили из фабричной однотонной или полосатой (чаще тяжёлой полушёлковой) ткани и подпоясывали кушаком. В холодное время года носили бешметы, чикмени, крытые либо дублёные шубы.

Головным убором мужчин, как уже упоминалось, была четырёхклинная, полусферической формы тюбетейка (тубэтэй) или в виде усечённого конуса (кэлэпуш). Праздничная бархатная позументная тюбетейка вышивалась тамбурной, гладьевой (чаще золотошвейной) вышивкой. Поверх тюбетейки (покрывала у женщин, вышитого тамбуром – эрпэк) в холодное время надевали полусферическую или цилиндрическую меховую или просто стёганую шапку (бурек), а летом войлочную с опущенными полями шляпу.

Женский головной убор в прежние времена, как правило, содержал информацию о возрастном, социальном и семейном положении его обладательницы. Девушки носили мягкие белые калфаки, тканые или вязаные. Замужние женщины поверх них, выходя из дома, набрасывали легкие покрывала, шелковые шали, платки. Носили также налобные и височные украшения – полоски ткани с нашитыми бляхами, бусинами, подвесками.

Обязательной частью женской одежды было покрывало. В этой традиции отразились древние языческие воззрения о магии волос, закрепленные позднее исламом, рекомендующим скрывать очертания фигуры и прикрывать лицо. В XIX веке на смену покрывалу пришел платок, универсальный головной убор практически для всего женского населения России. Однако женщины разных национальностей носили его по-разному.

Татарки плотно повязывали голову, надвинув платок глубоко на лоб и завязав концы на затылке – так его носят и сейчас.

Традиционная обувь – кожаные ичиги и башмаки с мягкой и жёсткой подошвой, нередко сшитые из цветной кожи. Праздничные женские ичиги и башмачки были орнаментированы в стиле многоцветной кожаной мозаики. Рабочей обувью служили лапти татарского образца (татар чабата): с прямоплетёной головкой и низкими бортиками. Их надевали с белыми суконными чулками (тула оек).

Наиболее ярко национальные особенности в одежде прослеживаются в женском костюме, в силу эмоциональности женщин и их внутренней потребности к красоте. При всей цветовой экзотичности он не выпадает из общей мировой тенденции моды: стремление к приталенному силуэту, отказ от больших плоскостей белого цвета, широкое применение продольного волана, использование в отделке объемных цветов, позументов, драгоценностей. Для одежды татар характерен традиционный трапециевидный силуэт с «восточной» насыщенностью цветов, обилие вышивок, применение большого количества украшений. Издавна татары ценили мех диких зверей – черно-бурой лисицы, куницы, соболя, бобра.

## Текст 4

## Мужская одежда

Основой нижней одежды входили *рубаха (кулмак)* и *штаны (ыштан)*, сшитые из сравнительно легкой льняной или хлопчатобумажной ткани.

По особенностям покроя в середине XIX и начале XX вв. имели место 2 типа мужских рубах:

1. Туникообразный - без шва на плечах, с ластовицами под мышками и с широкими вставными боковыми клиньями;
2. Рубаха со скошенными сшивными плечиками и круглыми проймами для рукавов.

Штаны (ыштан) также относятся к древней части одежды татар. По покрою они представляют собой вариант поясной одежды тюрко-язычных народов, получившие в этнографической литературе название "штаны с широким шагом". Их шили широкими у пояса, длиной до щиколоток, без карманов; укреплялись они на бедрах при помощи гашника (ычкыр), продетого в верхний загнутый край; покрой состоял из 3-х частей: двух штанин с клиньями и прямоугольной вставкой между ними. Для пошива нижних штанов использовалась алача собственного (домашнего) или среднеазиатского производства.

Общим признаком, по которому можно систематизировать верхнюю одежду татар, является покрой стана, его спинки. По этому признаку все многообразие верхней одежды сводится к следующим двум типам:

1. Одежда с приталенной спинкой;
2. Одежда с прямой спинкой.

В состав верхней одежды татар являлись *бишметы* - длинные распашные кафтаны с рукавами, *камзолы* - безрукавные или с короткими рукавами, облегающие тело распашные кафтаны, халаты

(чапан) из домотканой материи или среднеазиатских шелковых тканей. Поверх камзола мужчины носили длинный просторный халат (жилэн) с небольшим шалевым
воротником. Его шили из фабричной однотонной или полосатой (чаще тяжёлой полушёлковой) ткани и подпоясывали кушаком.

## Текст 5

## Головные уборы

Головные уборы мужчин, как и другие элементы одежды, делятся на домашние и выходные. К первой разновидности относится тюбетейка (тубэтэй). Тубэтэй представляет собой небольшую, надеваемую на верхнюю часть головы, шапочку. Ее шили из материи и украшали вышивкой - шелками, золотой и серебряной канителью, бисером, блестками. Не украшались тюбетейки из парчи и узорчатых шелковых тканей, а также не всегда украшались тюбетейки из бархата. Особенность казанско-татарским бархатным тюбетейкам придавал своеобразный способ крепления подкладки с верхом, при котором применялась мелкая стежковая техника. Обязательную принадлежность костюма (повседневного и праздничного) составляет обувь. Это прежде всего чулки (оек), отличающиеся большим разнообразием как по материалу, из которого они изготовлены, так и по форме.

## Текст 6

## Обувь

Обувь по материалу ее изготовления делится на: кожаную, лыковую, валяную. Чаще встречается кожаная обувь, хотя различные по зажиточности группы крестьян пользовались ею в разной степени.

Кожаная обувь у татар имела почти исключительно башмаковидную форму, т. е. отдельно кроились верх и подошва. Она различалась по твердости подошвы и по высоте голенища. По качеству (твердости) подошвы выделяются два типа кожаной обуви: 1) с мягкой подошвой и 2) с твердой подошвой.

К первому типу кожаной обуви относятся ичиги (читек) сапоги из мягкой однотонной, чаще черной кожи (юфти, сафьяна). Они кроятся цельными от головки до верхнего края голенища (вытяжными); к головке пришивалась отдельно выкроенная мягкая, из той же кожи, подошва. Шили их с изнанки, затем выворачивали (выворотные). Ичиги имели длинные голенища.

Валяная обувь так же, как и кожаная, имеет две разновидности: с коротким голенищем (бэлункэ, киез ката) и с высоким голенищем (киез итек, пима). Их носили в сочетании с ичигами или суконными чулками. Валяная обувь больше представляла зимнюю обувь старшего поколения. Среди мужчин среднего и молодого возраста значительное место занимала валяная обувь с высоким голенищем. Да и в дороге отдавалось предпочтение именно этой обуви, как и тулупу. Среди богатой прослойки города, особенно купцов, в нач. XX в. некоторое место имели узорные валенки.

## Текст 7

## Женская одежда

Женская традиционная одежда татар как в общем комплексе, так и в деталях, имеет больше разнообразия по сравнению с мужской. Она различалась не только по функциональному назначению (весенняя, летняя, осенняя, зимняя, повседневная, праздничная), но и по возрастному признаку (одежда девушек, молодых и старых женщин).

## Текст 8

## Нижняя одежда

В число нижней традиционной женской одежды татар входят: рубаха, нижний нагрудник (кукрэкча) и штаны (ыштан). Это сочетание имеет место в составе любого комплекса костюма, представляя его традиционную основу.

Нижнюю нагрудную повязку, нижний нагрудник (кукрэкча) шили из прямоугольного куска материи (домотканой или фабричной), размером, примерно, 25х40 см. На центральную часть повязки пришивался вышитый кусок материи или полоски яркой разноцветной ткани. Надевали кукракчэ под купмак и при помощи лямочек укрепляли к шее или за плечи, покрывая грудь женщины, слегка видневшуюся в прорезь ворота.

Одновременно с передниками, в комплексе рабочего костюма молодых женщин и девушек имели место вышитые нарукавники (жицса). Их надевали во время полевых работ (жатвы, сеноуборки), которые часто превращались в демонстрацию женского наряда. Вышитые тамбуром нарукавники в сочетании с вышитыми передниками гармонично дополняли многокрасочный комплекс женской одежды казанских татарок этого рабочего сезона.

## Текст 9

## Верхняя одежда

Верхняя одежда татарских женщин как по составу, так и по форме (покрою) имеет много общего с мужской, но часто с изменением некоторых деталей и добавлением декоративных элементов. Женские камзолы шили из цветного, чаще однотонного бархата и украшали по бортам и низу позументной тесьмой, мехом.

## Текст 10

## Головные уборы

Женские головные уборы делятся на: уборы девичьи и замужних женщин. Девичьи традиционные головные уборы в основном представлены в виде шапок. При их ношении волосы, заплетенные в две косы, располагались на спине и оставались открытыми или слегка прикрывались накосным украшением (тезмэ) или, позже, легким фабричным платком.

Традиционные головные уборы замужних женщин более разнообразны и сложны. В отличие от девичьих, уборы замужних женщин призваны были закрывать не только ее волосы, но и шею,

плечи, спину. Поэтому они включали в свой состав волосники и различные покрывала, которые, кстати, составляли основную часть комплекса головного убора замужних женщин.

Древнему (монументальному) стилю одежды соответствовали большие ажурные (сканые) часто с подвесками, отделанные камнями, украшения: серьги (алка), налобное ожерелье - баш хаситасе, воротниковая застежка - яка чылбыры, нагрудная перевязь - хасита, ши-рокие браслеты - белазек и перстни - йвзек. Считалось, что перстни очищают руки женщины, поэтому их могло быть на каждой руке по несколько штук.

## Текст 11

## Обувь

Обувь женская как по материалу изготовления, так и по форме также имела много общего с обувью мужской. Наибольшей популярностью пользовалась кожаная обувь, которая представлена несколькими видами: ичиги (читек), кауши (кавеш) и башмачки (башмак).

Отличительной чертой традиционной обуви татарских женщин является ее узорность и многоцветье. Ичиги, изготовленные из однотонного (зеленого, бордового и др.) сафьяна, часто расшивались цветочно-растительным узором. В народе расшитые ичиги назывались винзелле читек. Не менее оригинальными являются женские ичиги, изготовленные из узорно вырезанной разноцветной кожи (узоры составлены в технике кожаной мозаики). Такие ичиги назывались каюлы чи-тек или чвмчэле читек.

Особенностью традиционной одежды является то, что она, тесно связанная с жизнью народа, создавалась не одним человеком, а этнической общностью. Поэтому основные ее элементы по форме были общими для всей этой общности и носили ярко выраженный этнический характер. Повседневные и праздничные формы, одежда бедняков и богачей различались лишь качеством ткани и украшений. Однако это не означает, что традиционная одежда абсолютно схожа. Она очень многообразна, ибо, представляя творчество общности людей, традиционная одежда оставляла широкий простор и для развития яркой индивидуальности. Ни один элемент одежды, даже одного возраста и одной и той же территории, хотя и включал элементы общего типа, не повторял другой. Они соотносились не как копии, а как стереотипы или варианты.

## Текст 12

## Американская татарская ученая

Несколько лет назад в Америке на английском языке издана книга под названием “Волжские татары”. Ее автор американская татарка, профессор Лос-Анджелевского университета Азаде-Айша Рорлих.

Азаде-Айша ханум Рорлих родилась в 1942 году в татарской семье в городе Констанца Румынии. В 1964 году окончивает отделение русского языка и литературы Бухаретского университета. В 1967 году ее семья переезжает в Турцию.

С 1970 года Азаде-Айша ханум живет в Америке. В Висконсинском университете по русской истории добилась степени магистра, доктора. Интересуется русской историей, особенно богатой татарской историей. В Лос-Анжелевском университете преподает историю ислама.

Азаде-Айша ханум знает татарский, румынский, русский, английский, арабский, персидский, французский и немецкий языки.

Эрудированная ученая, знающая историю, литературу, язык и обычаи татарского народа пишет новые книги.

**КРИТЕРИИ ОЦЕНИВАНИЯ ЗАДАНИЙ**

**Оценка «5» (отлично) – 90% правильных ответов**
из 10 тестов 9 правильных ответов
из 15 тестов 14 правильных ответов
из 20 тестов 18 правильных ответов
из 30 тестов 27 правильных ответов
из 35 тестов 31 правильных ответов
из 50 тестов 45 правильных ответов
из 100 тестов 90 правильных ответов

**Оценка «4» (хорошо) – 80% правильных ответов**
из 10 тестов 8 правильных ответов
из 15 тестов 12 правильных ответов
из 20 тестов 16 ответов правильных
из 30 тестов 24 правильных ответов
из 35 тестов 28 правильных ответов
из 50 тестов 40 правильных ответов
из 100 тестов 80 правильных ответов

**Оценка «3» (удовлетворительно) – 70% правильных ответов**
из 10 тестов 7 правильных ответов
из 15 тестов 11 правильных ответов
из 20 тестов 14 правильных ответов
из 30 тестов 21 правильных ответов
из 35 тестов 24 правильных ответов
из 50 тестов 35 правильных ответов
из 100 тестов 70 правильных ответов

**Оценка «2» (неудовлетворительно) - 69% правильных ответов**
из 10 тестов 6 правильных ответов
из 15 тестов 10 правильных ответов
из 20 тестов 13 правильных ответов
из 30 тестов 20 правильных ответов
из 35 тестов 23 правильных ответов
из 50 тестов 34 правильных ответов
из 100 тестов 69 правильных ответов

## 2.7. КОМПЛЕКТ КАРТОЧЕК ДЛЯ ИНДИВИДУАЛЬНОЙ РАБОТЫ.

**Проверяемые результаты обучения:**Проверяем применение полученных знаний при решении задач устной и письменной коммуникации. Студенты должны уметь правильно написать

исследовательские работы, доклады ,сочинения-миниатюры. Участвовать литературных дискуссиях, правильно анализировать эпизодов и.т.д

**Задание для русской группы**

**Карточка №1**

**Задание 1.** ***Прочитайте текст. Определите, какие из приведенных утверждений А1-А11 соответствуют содержанию текста (1 – текстка туры килә), какие не соответствуют (2-текстка туры килми), и о чем в тексте не сказано ( 3 – текстта әйтелми)***

Милли ашлар

Җир шарында аксакаллар күп яши торган районнар билгеле. Аларның берсе Эквадорда. Озак яшәүнең сере гади: тауларда яшәргә кирәк, һәрвакыт хәрәкәттә булырга һәм иң мөһиме- дөрес тукланырга кирәк.Дөрес туклануга нәрсәләр керә? Күбрәк үсемлек ризыклары, яшелчә һәм җиләк-җимеш, сөт ризыклары, ә итне бик сирәк ашарга кирәк.

Баллы ашамлыклар тешләргә бик зарарлы, ә камыр ризыклары ашкайнату органнарына зарарлы. Ә менә коко-кола кебек эчемлекләрне химик препаратларга тиңлиләр. Чит илдә коко-коланы машина моторларын юарга, туалет һәм ванна юарга да, аварияләрдән соң юллардагы канны юарга да тоталар. Чипсы нерв системасын какшата һәм төрле теш авыруларын китереп чыгара. Пепси-кола аллергия, шикәр диабеты, ашказаны һәм бавыр авырулары, баш авырту китереп чыгара, хәтерне начарайта, күрү сәләтен киметә.

Димәк, дөрес тукланмау сәламәтлеккә бик зарарлы тәэсир итә. Шуңа күрә дөрес туклану мөһим. Шуңа карамастан, һәр халыкның яраткан ашы була.Татар халкының да төрле ризыклары бар. Алар: өчпочмак, гөбәдия, кыстыбый, токмачлы аш, бәлеш, чәкчәк һ.б.

Минем гаиләм-рус гаиләсе. Рус гаиләсе булса да, татар халык ашларын ашарга да, пешерергә дә яратабыз. Иң яраткан азыгыбыз өчпочмак. Бу ризыкны без ял көннәрендә гаиләбез белән әзерлибез. Әнием камыр баса, камыр җәя. Әтием ит турый. Ә мин бәрәңге, суган әрчим һәм турыйм. Әнием камыр басканда, суга яки сөткә май, йомырка, тоз сала һәм камырны өлешләргә бүлеп җәя. Аннары әтием белән эчлекне әзерлибез. Туралган бәрәңге, ит, суган һәм тәмләткечләр салабыз да өчпочмаклар ясыйбыз.Өчпочмаклар 40-45 минут духовкада пешә.Алар пешкәч, майлыйбыз һәм табынга куябыз. Әтием өчпочмакны сөт белән, әнием һәм мин чәй белән ашарга яратабыз. Өчпочмак пешкән көн-безнең өчен бәйрәм көн кебек.Бәйрәмнәргә без гаилә белән пилмән, төрле салатлар ясарга яратабыз. Ә чәй эчәргә әнием чәк-чәк пешерә белми. Шуңа күрә без аны кибеттән сатып алабыз. Әгәр әниемнең вакыты булса, ул тортны үзе ясый. Үзе ясаган торт бигрәк тә тәмле була.

Рус халык ашларын без һәркөнне әзерлибез.Аңа пилмән, кәбестә ашы, чөгендер ашы, кәбестә һәм балык пироглары керә. Әбием кайнар ашлар әзерләргә пироглар пешерергә ярата. Әтием нәрсә пешерсәк тә, рәхмәт әйтеп, яратып ашый.

**А1** Озак яшәүнең сере гади: спорт белән шөгыльләнергә, дөрес тукланырга, тәмәке тартмаска кирәк.

1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**А2.** Дөрес туклану мөһим түгел.

1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**А3.** Минем гаиләм - рус гаиләсе.

1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**А4.** Әтием суган, ит турый.

1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**А5.**Апам бәрәңге әрчи.

1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**А6.** Өчпочмаклар 20-25 минут духовкада пешә.

1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**А7.** Рус халык ашларын без һәркөнне әзерлибез.

1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**А8.** Әнием чәк-чәк пешерә белми.

1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**А9.** Без чәкчәкне кибеттән сатып алабыз.

1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**А10.** Әбием гөбәдия пешерергә ярата.

1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**А11.** Без, рәхмәт әйтеп, өстәл янынннан торабыз.

1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**Карточка №2**

**Задание 1.**

***Прочитайте тексты и установите соответствие между заголовками 1 – 6 и текстами А – Г. Запишите свои ответы в таблицу. Используйте каждую букву только один раз. В задании есть один лишний заголовок.***

1. азанда экскурсиядә.
2. Иң күркәм манара.
3. Сөембикә – гүзәл хатын.
4. Кызыл кирпечтән төзелгән манара.
5. Манараның эшләнеше.
6. «Егылучы манара»

**А**.Сөембикә манарасы – Казандагы милли архитектура һәйкәлләренең иң күркәме һәм иң атаклысы. Калабызга килгән кунаклар аның мәһабәт һәм күккә ашып торган матур эшләнешенә сокланалар.
**Ә**. Сөембикә манарасы җиде кат итеп кызыл кирпечтән төзелгән. Нигезнең тигез утырмавы сәбәпле, ул акрынлап көнчыгыш тарафына авышкан. Бу авышлык 1960 нчы елларда 1 метр 69 сантиметр булса, хәзер инде 1 метр 84 сантиметрга җитте.
**Б**. Мондый манаралар дөньяда санаулы гына. Шулар арасыннан Италиядәге Пиза манарасын «Егылучы манара» дип тә атыйлар.

**В**. Манараның биеклеге – 58 метр, нигез мәйданы – 140 квадрат метр, архитектурасы сирәк очрый торган алымнар белән эшләнгән.Манара стеналарының эчке ягында, каттан катка менү өчен, тар һәм текә баскычлар ясалган. Нәфис итеп эшләнгән тәрәзә уемнарыннан шәһәр һәм аның тирә-ягындагы манзараны күзәткәндә, ирексездән бабаларыбыз гомер кичергән ерак заманнар, Сөембикәнең аянычлы язмышы турында уйланасың.
**Г**. Сөембикә Нугай князьләренең олысы Йосыф кызы булган. Тарихта, әдәбиятта ул гүзәл, мөлаем, кешелекле һәм акыллы хатын итеп сурәтләнә.

| **Текстлар** | **А** | **Ә** | **Б** | **В** | **Г** |
|---|---|---|---|---|---|
| **Исемнәр** | | | | | |

**Карточка №3**

**Задание 1.**

**Для ответа на задания С1 и С2 используйте бланк ответов №2.**
**При выполнении задания С1 и С2 обратите внимание на то, что ваши ответы будут оцениваться только по записям, сделанным на бланке №2. Записи в черновиках при проверке экспертом не учитываются.**

**Соблюдайте указанный объём письменной работы С1(70-80 слов).**

**С1.** Сез татар дустыгыздан хат алдыгыз. Шушы сорауларга җавап биреп, аңа хат языгыз. Язма эшегез 70-80 сүздән торырга тиеш.
...Быел мин туган көнемне кафеда билгеләп үттем. Бәйрәмгә дусларымны чакырдым. Туган көнем бик күңелле узды: биедек, җырладык,музыка тыңладык, төрле уеннар уйнадык.

....Синең туган көнең кайчан була? Туган көнеңә кемнәрне чакырасың? Туган көнең,гадәттә ничек уза?

**В задании С2 необходимо написать реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией.**

1.Спросите у друга (подруги), в какой квартире он живет.
2. Сообщи друзьям, что вы на каникулах побывали в Англии.
3. Предложите другу(подруге) пойти на спектакль.
4. Поинтересуйтесь у бабушки,теплая ли ее квартира.
5. Поздравьте дедушку с днем рождения.

**Карточка №4**

**Задание 1.**
***Прочитайте текст. Определите, какие из приведенных утверждений А1-А11 соответствуют содержанию текста (1 – текстка туры килә), какие не соответствуют (2- текстка туры килми), и о чем в тексте не сказано ( 3 – текстта әйтелми)***
Габдулла Тукай

Габдулла Тукай-татар халкының бөек шагыйре. Ул Татарстанның Арча районы Кушлавыч авылында туган. Габдуллага 4 ай булганда, аның әтисе үлә.Әнисе күрше Сасна авылына кияүгә чыга. Озакламый әнисе дә үлә. Кечкенә Габдулланың ятимлек чоры башлана. Ул гаиләдән- гаиләгә күчеп йөри.Габдулланың балачагы Өчиледә, Казанда, аннан Кырлай авылында үтә.Тугыз яшендә бертуган апасы аны Уральск шәһәренә алып кайта. Алар Габдулланы укуга сәләтле, зирәк булуын күрәләр һәм мәдрәсәгә укырга бирәләр. Бер үк вакытта 3 еллык рус мәктәбендә укый. Мәдрәсәдә гарәп, фарсы, төрек телләрен үзләштерә.Мәктәптә рус телен өйрәнә, рус һәм Европа әдәбияты белән таныша.

Тукай шигырьләр яза башлый. Кулъязма журналда басылып чыга. Уральск шәһәрендә Габдулла журналист һәм шагыйрь буларак таныла. Ул төрле әдәби журналларда эшли. Фельетоннар, публицистик мәкаләләр, шигырьләр яза.

1907 нче елда Тукай Казанга күчеп килә. Казан- культура, сәнгать, белем үзәге. Шагыйрь Казанда 5 елдан артык яши һәм иҗат итә. Бу чорда балалар һәм өлкәннәр өчен шигырьләр яза. Балалар өчен «Су анасы», «Шүрәле», «Кәҗә белән сарык» экиятләрен « Бала белән күбәләк», «Туган тел», «Туган авыл» һәм башка күп әсәрләр яза.Аның әсәрләре туган якка, һәм ана теленә мәхәббәт тәрбияли, хезмәтне һәм укуны яратырга, әдәпле булырга өйрәтә.

Кечкнәдән ятимлектә үскән. күп авырлыклар күргән шагыйрьнең сәламәтлеге бик начар була. Ул 1913 елның 15 нче апрелендә 27 яшендә үлә. Халык аның әсәрләрен яратып укый. Татарстанда Тукай исемен йөртүче урамнар бар, аңа багышлап музейлар, һәйкәлләр ачылган. Тукай турында поэмалар, романнар, симфонияләр язылган.

**А1** Габдулла Тукай-татар халкының бөек язучысы.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А2.** Габдуллага 4 яшь булганда, аның әтисе үлә.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А3.** Әнисе күрше Сасна авылына кияүгә чыга.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**А4.** Унтугыз яшендә бертуган апасы аны Уральск шәһәренә алып кайта.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А5.** Мәдрәсәдә гарәп, фарсы, төрек телләрен үзләштерә.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А6.** Тукай шигырьләр яза башлый.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А7.** Уральск шәһәрендә Габдулла драматург буларак таныла.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А8.** Тукай бик күп язучылар белән таныша.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А9.** 1917 нче елда Тукай Казанга күчеп килә.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А10.** Бу чорда балалар һәм өлкәннәр өчен шигырьләр яза
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А11.** Тукай турында поэмалар, романнар, драмалар, симфонияләр язылган.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**Карточка №5**

**Задание 1.**

***Прочитайте тексты и установите соответствие между заголовками 1 – 6 и текстами А – Г. Запишите свои ответы в таблицу. Используйте каждую букву только один раз.В задании есть один лишний заголовок.***

1.Аккош – сак кош.
2.Аккош кулга тиз ияләшә.
3.Аккошларны аулау тыелган.
4.Аккошлар суда йөзә.
5.Аккошлар җылы якка очалар.
6. Иң зур һәм көчле кош.

**А**. Аккош – иң зур һәм көчле кошларның берсе. Ул бик борынгы заманнардан бирле матурлык һәм мәхәббәт, сафлык һәм нәфислек үрнәге булып тора. Аның матурлыгы турында җырлар җырлыйлар, хикәятләр сөйлиләр.

**Ә.** Апрель аеның зәңгәр күгендә зур аккошлар күренү – онытылмаслык матур күренеш. Ләкин тын урмандагы аулак күлдә йөзгән аккош тагы да матуррак тоела. Ул суда җиңел һәм тавышсыз йөзә, аккош йөзгән урында су ялтырап, яктырып кала. Аккошның һәр хәрәкәте кабатланмаслык нәфис.

**Б**. Аккошлар кеше йөзә алмаслык аулак күлләрдәге куе камышлар арасына оя ясый. Алар – искиткеч сизгер һәм сак кошлар. Балаларын ана кош белән ата кош бергәләп тәрбияли.

**В.** Ак төстәге аккош кулга тиз ияләшә. Бу матур, мәһабәт, горур кошлар бакча һәм урмандагы сулыкларга ямь биреп торалар.

**Г**. Аккош – табигатьтә иң гүзәл зат, ләкин ул аз калган. Шуңа күрә аны аулау тыела.

| **Текстлар** | **А** | **Ә** | **Б** | **В** | **Г** |
|---|---|---|---|---|---|
| **Исемнәр** | | | | | |

**Карточка №6**

**Задание 1.**

**Прочитайте текст. Преобразуйте слова, напечатанные заглавными буквами в конце строк, обозначенных номерами B8-B13 так, чтобы они грамматически и лексически соответствовали содержанию текста. Заполните пропуски полученными словами. Каждый пропуск соответствует отдельному заданию B8-B13.**

**B8**

| | |
|---|---|
| Герой-шагыйрь Муса Җәлил 1906 елның 15 февралендә элеккеге Оренбург губернасы Мостафа .................... туа. | АВЫЛ |

**B9**

| | |
|---|---|
| Муса Җәлил алты ................ авыл мәктәбенә укырга керә. | ЯШЬ |

**B10**

| | |
|---|---|
| Бөек Ватан сугышы башлангач, политруклар ............. тәмамалый һәм 1941 елда фронтка китә. | КУРС |

**B11**

| | |
|---|---|
| Муса Җәлил һәм .............. әсирлектә восстание әзерлиләр. | ИПТӘШ |

**B12**

| | |
|---|---|
| Төрмәдә утырганда, Җәлил шигырьләр ............. дәвам итә | ЯЗ |

**B13**

| | |
|---|---|
| Муса Җәлилгә ................ өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелә. | БАТЫР |

**Карточка №7**

**Задание 1.**

***Прочитайте текст. Определите, какие из приведенных утверждений А1-А11 соответствуют содержанию текста (1 – текстка туры килә), какие не соответствуют (2- текстка туры килми), и о чем в тексте не сказано ( 3 – текстта әйтелми)***

Әдәплелек кагыйдәләре.

Безнең тормышыбызда элек-электән кабул ителгән әдәплелек кагыйдәләре бар. Кеше үзен коллективта, урамда, җәмәгать урыннарында матур һәм дөрес тота белергә тиеш. Акыллы, тәрбияле кеше үзен башкалар алдында яхшы яктан гына күрсәтә. Аның өчен гаиләдә, йортта кечкенәдән үк әти-әниләр, әби-бабайлар балаларны тормышка әзерлиләр, тәрбиялиләр.

Тормышта үз-үзеңне әдәпле, матур тоту кагыйдәләрен күп урыннарда үтәргә кирәк. Мәсәлән, мәктәптә укучы бала дәрескә куелган таләпләрне- өй эшен үти, аяк һәм өс киемнәрен чиста йөртә, дәресне игътибар белән тыңлый. Ә урамда юл йөрү кагыйдәләрен үтәргә кирәк. Кагыйдәләрне белмәсәң яки үтәмәсәң, төрле күңелсез хәлләр, тавыш, шау-шу туарга яки көлкегә калырга мөмкин.

Мәктәптә кайбер малайлар кызларны рәнҗетәләр, үртиләр, чәчләреннән тарталар, сугалар. Үзләрен тупас, әдәпсез тоталар. Әдәпле булу модада түгел дип уйлыйлар. Кайбер кызлар, киресенчә, артык оялчан, ямьсез, таза малайлардан көләләр. Әдәпле кешеләр сине тыңлый беләләр, синнән көлмиләр, кимчелекләреңне гафу итә беләләр.

Әгәр кеше киң күңелле, намуслы, туры сүзле, әдәпле булса, аның белән озак дуслашып була.

Әдәпле бала транспорта өлкәннәргә , балалы хатын-кызларга урын бирә. Аларга транспортка керергә һәм аннан чыгарга булыша. Транспортта кычкырып сөйләшми, көлми, башкаларга комачауламый.

Татар халкында «Әдәп башы-тел», «Әдәпленең күлмәге сәдәпле», «Киемеңә карап каршы алалар, акылыңа карап озаталар» дигән мәкальләр бар. Чынлап та кеше акыллы, тәртипле булса гына, ул матур күренә.

Кунакка баруның да аерым кагыйдәләре бар. Кунакка алдан сөйләшеп, тиешле вакытта барырга кирәк. Фатирга ишек шакып яки звонокка басып керергә кирәк. Кунаклар белән матур итеп исәнләшергә, киемне элгечкә эләргә, хуҗа нинди уеннар әзерләгән, шуларны уйнарга һәм башка кунаклар белән бервакытта, табын, сый өчен хуҗаларга рәхмәт әйтеп, саубуллашып китәргә кирәк.

Әгәр сез үзегезне акыллы, тәртипле, әдәпле тотсагыз, башкалар да сезне хөрмәт итәрләр, яратырлар.

**А1** Акыллы, тәрбияле кеше үзен яхшы яктан гына күрсәтә.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А2.** Аның өчен гаиләдә, мәктәптә эти-әниләр, укытучылар тәрбиялиләр.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А3.** Урамда әдәплелек кагыйдәләрен үтәргә кирәк.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А4.**Юл аша чыкканда, башта сулга, аннан уңга карарга кирәк.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А5.** Мәктәптә кайбер малайлар үзләрен тупас тоталар.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А6.** Әдәпсез булу модада түгел дип уйлыйлар.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А7.** Кеше акыллы, тәртипле булса гына, ул матур күренә.

1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А8.** Кунакка баруның да аерым кагыйдәләре бар.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А9.** Фатирга ишеккә аяк белән тибеп яки звонокка каты итеп басып керергә кирәк.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А10.** Хуҗаларга чәчәк букетын өскә таба каратып бирергә кирәк.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми
**А11.** Кунакка соңга калып барырга ярамый.
1)Текстка туры килә 2) Текстка туры килми 3) текстта әйтелми

**Карточка №8**

**Задание 1.**

| |
|---|
| ***Прочитайте текст. Преобразуйте слова, напечатанные заглавными буквами в конце строк, обозначенных номерами В2-В7 так, чтобы они грамматически соответствовали содержанию текста. Заполните пропуски полученными словами. Каждый пропуск соответствует отдельному заданию В2-В7.*** |

**В2**

| | |
|---|---|
| Лотфулла Фәттахов 1918 нче елда Түбән Новгород өлкәсенең Сергач .................... Анда авылында крестьян гаиләсендә туа | РАЙОН |

**В3**

| | |
|---|---|
| Аңа ике яшь булганда, гражданнар сугышында ………… һәлак була. | ӘТИ |

**B4**

| | |
|---|---|
| Сигез яше тулганда, гаиләдәге өч бала ................. дә калалар. | ӘНИ |

**B5**

| | |
|---|---|
| Лотфулланы Сергачтагы балалар йортына ………………. . | БИР |

**B6**

| | |
|---|---|
| Малай бик .............. һәм йомшак күңелле булып үсә. | ЭШ |

**B7**

| | |
|---|---|
| Буш вакытларында китап ................. , бигрәк тә рәсем ясарга ярата. | УКЫ |

**Карточка №9**

**Задание 1.**

| |
|---|
| **Прочитайте текст. Преобразуйте слова, напечатанные заглавными буквами в конце строк, обозначенных номерами B8-B13 так, чтобы они грамматически и лексически соответствовали содержанию текста. Заполните пропуски полученными словами. Каждый пропуск соответствует отдельному заданию B8-B13.** |

**B8**

| | |
|---|---|
| Лотфулла мәктәптә бик тырышып укый, түгәрәкләрдә бөтен ........................ биреп шөгыльләнә. | КҮҢЕЛ |

**B9**

| | |
|---|---|
| Казанның 13 нче мәктәбендә җиденче классны тәмамлагач, Казан сәнгать ................................. укый. | УЧИЛИЩЕ |

**B10**

| | |
|---|---|
| Аның иң яраткан ............. - авыл тормышы турындагы сюжетлар һәм экиятләргә иллюстрацияләр. | ТЕМА |

**B11**

| | |
|---|---|
| Лотфулла Фәттахов Франциядә партизаннар ……………… сугыша. | ОТРЯД |

**B12**

| | |
|---|---|
| Лотфулла Фәттахов өчен сугыш 1946 нчы елда Венгриядә ................................ . | ТӘМАМЛА |

| **B13** |
|---|

| | |
|---|---|
| Сугыштан ул Казанга, туп-туры дусты Харисның ........... кайта һәм шушы гаиләдә яши башлый. | ӨЙ |

**Карточка №10**

**Задание 1.**

| |
|---|
| ***Прочитайте тексты и установите соответствие между заголовками 1 – 6 и текстами А – Г. Запишите свои ответы в таблицу. Используйте каждую букву только один раз.В задании есть один лишний заголовок.*** |

1.Аккош – сак кош.
2.Аккош кулга тиз ияләшә.
3.Аккошларны аулау тыелган.
4.Аккошлар суда йөзә.
5.Аккошлар җылы якка очалар.
6. Иң зур һәм көчле кош.

**А**. Аккош – иң зур һәм көчле кошларның берсе. Ул бик борынгы заманнардан бирле матурлык һәм мәхәббәт, сафлык һәм нәфислек үрнәге булып тора. Аның матурлыгы турында җырлар җырлыйлар, хикәятләр сөйлиләр.

**Ә.** Апрель аеның зәңгәр күгендә зур аккошлар күренү – онытылмаслык матур күренеш. Ләкин тын урмандагы аулак күлдә йөзгән аккош тагы да матуррак тоела. Ул суда җиңел һәм тавышсыз йөзә, аккош йөзгән урында су ялтырап, яктырып кала. Аккошның һәр хәрәкәте кабатланмаслык нәфис.

**Б**. Аккошлар кеше йөзә алмаслык аулак күлләрдәге куе камышлар арасына оя ясый. Алар – искиткеч сизгер һәм сак кошлар. Балаларын ана кош белән ата кош бергәләп тәрбияли.

**В.** Ак төстәге аккош кулга тиз ияләшә. Бу матур, мәһабәт, горур кошлар бакча һәм урмандагы сулыкларга ямь биреп торалар.

**Г**. Аккош – табигатьтә иң гүзәл зат, ләкин ул аз калган. Шуңа күрә аны аулау тыела.

| **Текстлар** | **А** | **Ә** | **Б** | **В** | **Г** |
|---|---|---|---|---|---|
| **Исемнәр** | | | | | |

**Задание для татарской группы**

**1 нче карточка**

**1 нче бирем:** Өзекне сәнгатьле итеп укыгыз. Татар телендә җөмләдә сүз тәртибен искә төшерегез. Кайсы җөмләләрдә сүз тәртибе сакланмаган?

Август аеның җылы, кояшлы көннәре. Быел табигать авыл кешесенә мәрхәмәтле булды, урып-җыю вакытында нәкъ шундый аяз көннәр кирәк тә инде. **Тик бар дөнья тузанга чумган, коры, эссе һава тынга каплана.** Юл буендагы бу бичара каен да тоташ тузанга күмелеп утыра. Арыган, әлсерәгәндер инде мескенкәем. Ничә еллар буена Шатлык кешеләрен каршылый - озата ул. *(М. Хуҗин)*

**2 нче бирем**: Җөмләнең аерымланган кисәкләре турында белгәннәрегезне искә төшерегез. Җөмләнең кайсы кисәкләре аерымлана? Алар янында нинди тыныш билгеләре куела? Түбәндәге җөмләләрне дөрес итеп укыгыз, күчереп языгыз, аерымланган кисәкләрнең астына сызыгыз.

1. Нәфисәләр, урман авызыннан кереп, тар сукмактан бераз барганнан соң, иренчәк агымлы кечкенә генә инешне узып, бер ачыклыкка килеп чыктылар. *(Г.Бәширов)* 2. Җитез сабан тургайлары, такмаклап биюче егетләр сыман, нурлы һавадан төшмичә, сайрый-сайрый, сызгыра-сызгыра җилпенәләр. *(Ә.Еники)* 3. Яңгыр теләп, яз хәбәрчеләре- сыерчыклар оча. *(Г.Гобәй)* 4. Сылу сыерчыклар, назлы сандугачлар, иркә кәккүкләр, туйга чакырылган җырчылар кебек,су буендагы куе тирәкләрдә туктаусыз сайрап тора. *(Ә.Еники)*5. Сабан тургайлары, язгы табигатькә иртәнге сәламнәрен җиткерү өчен, зәңгәр күккә күтәрелделәр. Алар, язны мактап, озак-озак сайрыйлар. *(Натуралист язмаларыннан)* 6. Рөкыя шактый алдан кайтып җиткән булса да, капка төбендә калып, боларны көткән икән. *(Ф.Әмирхан)*

**2 нче карточка**

**1 нче бирем:** Җөмләләрне укыгыз, тыныш билгеләрен аңлатыгыз.

1. Кояш, элеккедән дә матуррак булып, болыт астыннан чыкты. *(Г.Бакиров)* 2. Ә вак балыклар, дошманнары - эре балыклардан куркып, көтүләре белән комлы сайлыкка йөзеп чыга. (*Д.Аппакова)* 3. Өч көн эчендә җир өсте яңадан тугандай булды. Һәркайда-аклык, пакьлек. *(А.Хәсәнов)* 4.Дуамал бураннары, чатнаган суыклары белән бергә кыш үтеп китте .*(Г.Ибраһимов)* 5.Кояш югарырак үрләде, юкәне буеннан-буена яктыртты. *(М.Рафиков)*

**2 нче бирем**: Җөмләләрне татарчага тәрҗемә итеп языгыз. Бу җөмләләрдә нинди тыныш билгесе җитми? Татар телендә ул кайсы очракларда куела?

1.Июньская ночь коротка. *(Г. Троепольский)* 2.Звезды великолепны. *(И.Гончаров)* 3.Пурга это снежный буран во время которого температура понижается до минус пятнадцати. *(В.Арсеньев)* 4.Точность и краткость- вот первые достоинства прозы.*(А.Пушкин)*5.А вы человек бывалый. *(А.Чаковский*)6. Художественная литература это искусство слова. *(К.Федин)* 7.Коса девичья краса.*(Пословица)*8. Лось очень сильное осторожное и умное животное. (И.Соколов-Микитов) 9. Доброе начало половина дела. *(Пословица)* 10.Ласковое слово что весенний день. *(Пословица)*

**3 нче карточка**

**1 нче бирем:**Җөмләләрне бәйләнешле текст барлыкка килерлек итеп урнаштырыгыз.

1. Миңа да бик авыр иде. 2. Үзе дә сизмәстән, очраклы рәвештә генә юлыма тап булган бу абзый миңа «яшәү мәгънәсе», «иманлылык» төшенчәләрен үз эченә алган һәм алдагы гомеремдә мең мәртәбәләр ярдәмгә киләчәк рухи ныклык, ихтыяр көче биреп киткән иде... 3. Шушы хатирәләреннән бушанган фронтовик карт кабат, тыйнак кына елмаеп, моңсуланды, басынкыланды, уйчанланды... 4. ...Әллә нинди булды ул көн. (Г.Гыйльман)

**2 нче бирем**: Өзекне дөрес һәм сәнгатьле итеп укыгыз, кыз озату күренешен кыскача сөйләп бирегез.

**4 нче карточка**

**1 нче бирем:**Текстны сәнгатьле итеп укыгыз. Тезмә кушма җөмләләрне табыгыз һәм аларның төрен билгеләгез. Аларның үзара нинди чаралар ярдәмендә бәйләнүен ачыклагыз.

Көймәче тагын мотор бавын тартты. Мотор төчкерде, пошкырды да янә сүнде, Хуҗаның түземлеге төкәнде.Мотор төчкереп алды да тырылдап эшләргә кереште. Көймәгә беренче Хуҗа сикереп менде, аның артыннан ярдәмчесе үрмәләде, аннан соң Мөхәммәтләр утырышты. Көймәче сүзен әйтер алдыннан, әүвәл күккә күз ташлады, аннары аның күз карашы көймәдән читкә чабышкан дулкыннар өстеннән сикереп узды. Ул янә күккә карады. Болытлар бик тиз хәрәкәт итә, күктә Зур Судагы дулкыннар чагыла. Көймә чайкалып китте, мотор сәер тавыш чыгарып пырхылдады... Хуҗа кеше малайны кырыйдан каерып алды, аның ярдәмчесе белән көймәче карт Мөхәммәтнең әтисенә көймәгә менәргә булыштылар. Хуҗа аңа кырын күзе белән генә карап куйды, Мөхәммәтнең әтисе бу караштан куырылып килде. Мулла бабай медер-медер капчыклы карт белән сөйләшә, дөресрәге, үзе генә сөйли... Җир өстен су баса, коры җир тарая.Мулла бабайның тавышы бик зәгыйфь чыкты, аның гәүдәсе бөтенләй бөрешеп, кечерәеп калган иде... Теге чаклардагы чыра яктысы, сукыр лампа яктысы синең күзеңне бетергән, күрмисең син, менә шул!Мөхәммәт атлы малайның күзләре елтырап китте, ирексездән авызы ерылды. Су өстендәге дулкыннар ишәйде, көймәгә берөзлексез шап та шоп сугып торган кара сыртлы дулкыннар зурайганнан-зурайды... Аның беләкләре көч белән тулды, ул ашыга-ашыга иште. *(З.Хөснияр*)

**5 нчы карточка**

**1 нче бирем**: Мәкальләрне укыгыз, мәгънәләрен аңлатыгыз. Кушма җөмлә тәшкил иткәннәрен дәфтәрегезгә күчереп языгыз. Кушма җөмләләр составындагы гади җөмләләр нинди мәгънә мөнәсәбәтендә торалар һәм нинди чаралар ярдәмендә бәйләнгәннәр, шуны ачыклагыз.

1. Ашның мае бар, сүзнең җае бар. *(М.)* 2. Кунак килсә, ит пешә, ит пешмәсә, бит пешә. *(М.)* 3. Күлнең күрке - камыш, ирнең күрке - намус. *(М.)* 4. Яхшы гадәт адәм итәр,яман гадәт әрәм итәр. *(М.)* 5. Ялагайның күзе ─ көзге, теле ─ тасма. *(М.)* 6. Күмәк эш күңелле эш .*(М.)*7. Адәмне адәм иткән әдәп. *(М.)*

**2 нче бирем**: Җөмләләрнең баш кисәкләрен табыгыз. Нәтиҗә ясагыз: җөмләләрнең ничә грамматик нигезе бар? Бу җөмләләрнең аермасы нәрсәдә?

Ирек алпан-тилпән арбага таба атлап китте. Чемоданын алмакчы булды, ләкин көче җитмәде, чемодан зур. Аның эче тулы китап иде. Ул, тешләрен кысып, чемоданын юл буена куйды да чирәмгә утырды. Ирекнең тамагына кайнар нәрсә килеп тыгылды, күзләренә яшь тулды, ул үзен кызганды,

аннары Зәнфирәне кызганды. Шулвакыт ул, арба тавышы ишетеп, уңга борылып карады. Сабирҗан абзый, чапкан печәннәрен салып, аның янына килә иде.

─ Юл буенда утырма, үскәнем, ─ диде ул, арбасыннан төшеп. Ирекнең чемоданын күтәреп печән өстенә җайлап куйды да:

─ Әйдә, мен арбага, чемоданың да бик авыр, районга илтеп куям, - диде. *(Ф.Садриев)*

**6 нче карточка**

**1 нче бирем:**Өзекне укыгыз.”Туган ягыбыз халкы” дигән темага фикер алышыгыз.

Менә без шагыйрьнең туган авылы Кушлавычта! Тукай әйткәнчә, авыл тау башына салынган. Төз һәм матур йортлары белән ул ерактан ук күңелне үзенә тартып тора. Элекке замандагы салам түбәле, төртсәң аварга торган иске өйләр урынында шулай мәһабәт булып калкып чыккан бу йортлар!

Авылның хезмәт сөючән кешеләре Тукайны тирән хөрмәт белән искә алалар, аның белән горурланалар. Авыл китапханәсенә дә аның исемен биргәннәр.

Әсәрләре белән якты маяк булып балкыган шагыйребез менә шушы авылда туган, сабый чагында ук төрле кимсетүләр һәм ятимлекне шушы авылда кичергән. *(С.Шакир)*

**7 нчы карточка**

**1 нче бирем:** Текстны укыгыз. Исем бирегез

Көз җитү **белән** табигатьтә һәммә нәрсә сулып кала. Үләннәр кибешә, чәчәкләр шиңешә, агачлар шәрә хәлгә килешә. Күз иркәләрлек берни дә күренми. Ярый ла нарат урманына тап булсаң. Яки чыршы урманына юлыксаң. Яшел төс бары анда саклана. Ә күңел дигәнең яфраклы урманны, андагы яшеллекне **юксына**. Ә яшеллекнең эзе дә калмаган. Күңелең кителә, нәрсәдер җитмидер **төсле** тоела. Шул чагында әллә кайлардан, ерактан күзеңә түм-түгәрәк, ямь-яшел шар ташлана. **Аякларың** ирексездән шул якка таба атлый. **Яфраклы** урманда артышлар **яшел киемнәрен** салмаган икән ләбаса! Ничәмә-ничә артыш куагы бар-һәммәсе уч төбендәгедәй күренә. Күзеңне бөтен урман буйлап йөртәсең, артыш **куакларын**, ямьле, яшел шарларны эзлисең. *(Г.Хәсәнов)*

**8 нчы карточка**

**1 нче бирем: Текстны сәнгатьле итеп укыгыз**

Тамчылар, тамчылар! Кайсысы иң бәхетле дә, кайсысы җирдә яз ясауда иң мөһиме соң аларның? Сабыйны куандырганымы, чибәр кызны елмайтканымы? Әллә, күңеленә зур өметләр салып, агроном егетне эшкә алгысытканымы? Яисә салкын кыш уртасында ук каен бөреләрен килеп уятканы микән? Әллә соң мондый өлгерләргә кушылып аларга көч-куәт кенә биреп тамучы меңләгән- миллионлаган башка тамчылар бик бәхетлеләреме?

Әйе, һәркайсы нәни кояштай нурланып җемелдәшүче мөлдерәмә тамчыларның да барлыгы беленде. Кичен, бик озак йоклый алмый ятканнан соң, инде күңелле генә бер төш күрә башлауга, әнисенең сак кына башыннан сыйпавын сизде Ильяс. Төш өзелде, аның битенә һәм колак турысына бер-бер артлы ике бөртек тамчы тамып төште. Җып-җылы, хәтта кайнар иде бу тамчылар, ләкин

алар да нәни кояштай нурланып җемелдәшә иделәрме, әллә бүтәнчәме? Кызганычка каршы, караңгыда күреп булмады...

Күңеленнән генә:” Ник, ник елыйсың, әнием!”- дип өзгәләнде ул.

Иртәгесен әнисе инде күптән эшкә киткән, өйдә тынлык.

Тышта күршеләрнең берәрсенең тук-тук балта чапканы ишетелә, аргы як урамнан гүелдәп машиналар узгалап тора, ә өйдә тып-тын. Тып-тын, тик әнә умывальник борынынннан чутылдап тамчы тамгалый да, келт-келт сәгать йөри.

Өйдә тыңлык, тик менә умывальник борынынннан чутылдап тамчы тама да, дөп-дөп Ильясның йөрәге тибә. Салкын тамчы, учларыбызга тамып, йөрәкләрдә тормышка дәрт уята, ә биткә тамган кайнар тамчы күңелләрдә нидидер бер моң уята икән. (Р. Төхфәтуллин).

**9 нчы карточка**

***1 нче бирем:*** Х.А. Якуповның «Хөкем алдыннан» картинасы буенча хикәя языгыз. Аны бергәләп укып карагыз.

Күренекле рәссам Х. Якуповның «Хөкем алдыннан» картинасы Советлар Союзы Герое шагыйрь Муса Җәлилнең әсирлектәге тормышын, батыр көрәшен сурәтли.

Моабит төрмәсе. Җәлил хөкем алдында, фашистлар аннан сорау алалар. Капма-каршы ике дөнья кешеләре очрашканнар. Берсе − Муса Җәлил − шагыйрь, көрәшче. Икенчеләре − фашистлар, кешеләрне җәзалап тәм табучы, дөньяны канга батыручылар.

Алгы планда Муса Җәлил горур басып тора. Аның нәфрәт тулы күзләрендә кискенлек һәм катгый караш чагыла. Ул фашистларга кыю рәвештә батырып карап тора. Җәлилнең буйсынмас килеш-кыяфәте туган иленә бирелгәнлеген раслый.

Төрмә киемнәреннән булса да, шагыйрьнең өсте-башы пөхтә, җыйнак. Өстендә иске телогрейка, муенына төрмә номеры тагылган. Рәссам герой-шагыйрьнең эчке ныклыгын, көчле ихтыярын бирә алган. Бу күренештә Муса Җәлилнең килеш-торышы нәкъ үзе язган шигырьгә туры килә:

Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,
Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә,
Үләм икән − үләм аягүрә,
Балта белән башым киссәң дә.

Хөкем итүче фашистлар шагыйрьгә каршы утырганнар. Аларның йөзендә борчылу, тынычсызлану сизелеп тора. Креслога хуҗаларча киерелеп утырганы М. Җәлилгә гаҗәпләнеп, буйсындырырга көче җитмәүдән, аңа ачу белән карый, аның җиңендә − свастика (фашистлар эмблемасы, очларын тигез итеп бераз бөгеп ясалган тәре). Аның борчылуын кулында төтенләп, дерелдәп яна торган трубкасы да сиздерә. Зур чиндагы фашистларның икенчесе ачуыннан урыныннан сикереп торган, шагыйрьнең буйсынмас характерына аптырап, моны нишләтергә дигән

сыман, аңа нәфрәт белән карап тора. Ә өченчесе, ачулы каушавын басу өчен, зажигалка кабызып, телефоннан сөйләшә, кемнәндер киңәш, ярдәм сорый булса кирәк: йөзе тынычсыз, хәсрәтле күренә. Ишек төбендәге төрмә сакчысының да кичерешләре бик киеренке, җанлы: аның күз карашында шагыйрьнең ныклы ихтыярына, туган иленә турылыклы булуына гаҗәпләнү катнаш соклану чалымнары да сизелә. Гүя ул, үз хезмәтенең түбәнлегенә үртәлеп, күңелсез уйларга баткан.

Тиздән фашизмның җиңеләчәген бүлмә эчендәге җиһазлардан да белергә мөмкин. Стенадагы рамда Гитлер рәсеменең яртысы гына күренә. Бүлмә шактый җиһазлы: люстра, креслолар, зур, авыр өстәл. Остәлдә фашистларның төрле үзәкләрен тоташтыра торган телефоннары, бөркет рәсемле кара савыты һәм өзлексез тартуны белдереп торган тәмәке төпчекләре, ә бераз читтәрәк аларның купшы перчаткалары һәм фуражкалары ята. Рәссам Харис Якупов Җәлилнең горур торышына капма-каршы итеп, фашистларның эчке борчылулары аша аларның җиңелә баруларын, тиздән халыклар хөкеме алдына басарга тиешлекләрен ачык гәүдәләндергән.

**10 нчы карточка**

***1 нче бирем:*** Ни өчен мәзәкләр озак яшәүчән? Сез ничек уйлыйсыз?

Мәзәкләр − халык авыз иҗатының киң таралган бер төре. Алар бик озак яшиләр. Моның төп сәбәбе тормышның төрле якларын күрсәтүдә дип уйлыйм. Безнең халкыбыз юмор ярата. Ә мәзәкләрне тыңлагач, рәхәтләнеп көләсең. Мәзәкләр кешеләрдәге кимчелекләрне бетерергә дә ярдәм итәләр. Аларда олылар да, кечкенәләр дә тәнкыйтьләнә. Бу жанрның күләм ягыннан кечкенә булуы да аларның озак яшәвенә сәбәп буладыр. Кеше кыска сюжетлы әсәрләрне исендә калдыра, аларны башкаларга сөйли. Шулай итеп, ул мәзәкләр бер кешенеке генә булып калмыйча, дөньяга таралалар. Дөньяга, күп кешеләргә таралган мәзәкләр озак яшәүчән булалар.

## КРИТЕРИИ ОЦЕНИВАНИЯ ЗАДАНИЙ

**Оценка «5» (отлично) – 90% правильных ответов**
из 10 тестов 9 правильных ответов
из 15 тестов 14 правильных ответов
из 20 тестов 18 правильных ответов
из 30 тестов 27 правильных ответов
из 35 тестов 31 правильных ответов
из 50 тестов 45 правильных ответов
из 100 тестов 90 правильных ответов

**Оценка «4» (хорошо) – 80% правильных ответов**
из 10 тестов 8 правильных ответов
из 15 тестов 12 правильных ответов
из 20 тестов 16 ответов правильных

из 30 тестов 24 правильных ответов
из 35 тестов 28 правильных ответов
из 50 тестов 40 правильных ответов
из 100 тестов 80 правильных ответов

**Оценка «3» (удовлетворительно) – 70% правильных ответов**
из 10 тестов 7 правильных ответов
из 15 тестов 11 правильных ответов
из 20 тестов 14 правильных ответов
из 30 тестов 21 правильных ответов
из 35 тестов 24 правильных ответов
из 50 тестов 35 правильных ответов
из 100 тестов 70 правильных ответов

**Оценка «2» (неудовлетворительно) - 69% правильных ответов**
из 10 тестов 6 правильных ответов
из 15 тестов 10 правильных ответов
из 20 тестов 13 правильных ответов
из 30 тестов 20 правильных ответов
из 35 тестов 23 правильных ответов
из 50 тестов 34 правильных ответов
из 100 тестов 69 правильных ответов

**3. Контрольно-оценочные материалы для проведения промежуточной аттестации.**
**Проверяемые результаты обучения:** Контрольно-оценочные материалы для проведения дифференцированного зачета по «Родной литературе» среди студентов I курса составлены в форме билетов. После пройденного курса студенты должны владеть всеми языковыми средствами и достичь поставленных коммуникативных задач.

**3.1 Общие положения**

Форма промежуточной аттестации по учебной дисциплине ОУД. 12 «РОДНАЯ ЛИТЕРАТУРА»- дифференцированный зачет.

Дифференцированный зачет предназначен для контроля и оценки результатов освоения учебной дисциплины ОУД.12 «РОДНАЯ ЛИТЕРАТУРА» по специальности:
09.02.07. Информационные системы и программирование.

**3.2. Комплект контрольно- оценочных материалов.**

**Форма проведения дифференцированного зачета - Опрос по билетам для русской группы**

| | | |
|---|---|---|
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет №1<br>1.Идейно-художественное своеобразие поэмы Кул Гали «Кысса-и-Йусуф»: проблематика, система образов, поэтика.<br>2. Расскажи о городе Казани .<br>3. Рассказать стихотворение наизусть. | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_______________ |

| | | |
|---|---|---|
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№2<br>1. Роль К. Насыйри в истории татарской литературы.<br>2. История татарского языка. Литературное, историческое, культурное наследие.<br>3. Рассказать стихотворение наизусть. | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№3<br>1. Наследие периода Золотой Орды и Казанского ханства: история, культура, литература<br>2. .Роль и место родного литературного языка в полилингвальном и поликультурном обществе.<br>3. Рассказать стихотворение наизусть. | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№4<br>1.Особенности литературы XVII-XVIII вв.<br>2. Роль РТ в России и мире.<br>3. Рассказать стихотворение наизусть. | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№5<br>1.Проблематика литературы XIXв.<br>2.Государственные символы РТ<br>3. Рассказать стихотворение наизусть. | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№6<br>1. Деятельность К.Насыйри в области литературного перевода. Собрание татарского народного творчества в произведениях. Значение работы ученого.<br>2.Устное народное творчество, мифология, религия, их влияние на литературу.<br>3.Рассказать стихотворение наизусть | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |

| | | |
|---|---|---|
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№7<br>1.Особенности литературы XX в.<br>2. Первые печатные издания на татарском языке. Татарская азбука.<br>3.Рассказать стихотворение наизусть | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№8<br>1.Роль историческихи фольклорных источниковв произведениях поэта. Проблематика. Сюжет и композиция.<br>2.Древняя татарская литература. Роль традиции в литературе.<br>3.Рассказать стихотворение наизусть | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№9<br>1.Творчество Г.Тукая. История изучения художественного наследия поэта. Национальные мотивы творчества.<br>2.Наследие болгарского периода: история, культура, литература.<br>3.Рассказать стихотворение наизусть | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№10<br>1.Х.Такташ. Жизнь и творчество. Анализ произведений<br>2. Наследие периода Золотой Орды и Казанского ханства: история, культура, литература<br>3.Рассказать стихотворение наизусть | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№11<br>1.Композиционные особенности произведения. Проблематика. Образы.<br>2.Проза и поэзия. Идеологическое и философское содержание произведений<br>3.Рассказать стихотворение наизусть | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |

| | | |
|---|---|---|
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№12<br>1.Х. Туфан. Любовная лирика поэта.Жанрово-стилевые особенности произведений.<br>2.Творческое наследие современных поэтов.<br>3.Рассказать стихотворение наизусть | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>__________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№13<br>1.Творчество Г.Баширова, произведение «Туган ягым – яшел бишек»<br>2.Творческое наследие современных писателей<br>3.Рассказать стихотворение наизусть | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>__________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№14<br>1.Проза и поэзия. Идеологическое и философское содержание произведений.<br>2.Творчество М.Джалиля. М.Джалиль и курмашевцы. Идеологическое и философское содержание поэтических произведений.<br>3.Рассказать стихотворение наизусть | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>__________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№15<br>1.Творчество А.Еники.Анализ произведений«Ребенок», «Гостеприимный враг».<br>2.Творческое наследие современных поэтов<br>3.Рассказать стихотворение наизусть | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>__________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№16<br>1.Творческое наследие современных драматургов. Творчество Т.Миннуллина.<br>2. Знаменитые люди Казани<br>3.Рассказать стихотворение наизусть | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>__________________ |

| | | |
|---|---|---|
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№17<br>1. Своеобразие драматургии К. Тинчурина<br>2.Республика Татарстан, Казань – город с тысячелетней историей.<br>3.Рассказать стихотворение наизусть | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№18<br>1.Золотой век татарской поэзии (Дардэменд, С. Рамиев).<br>2. Национальная библиотека РТ<br>3.Рассказать стихотворение наизусть | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>___________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№19<br>1. Становление татарской драматургии. Творчество Г.Камала<br>2.Достопримечательности Казани<br>3.Рассказать стихотворение наизусть | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№20<br>1.Своеобразие драматургии Г. Камала.<br>2. Национальные праздники РТ<br>3.Рассказать стихотворение наизусть | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№21<br>1.Основные темы и мотивы поэзии Х. Такташа.<br>2. Становление татарской драматургии. Творчество К.Тинчурина.<br>3.Рассказать стихотворение наизусть | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |

| | | |
|---|---|---|
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет№22<br>1.Роль Г. Тукая в истории татарской литературы.<br>2. История татарского театра. Татарская литература на сцене татарского театра.<br>3.Рассказать стихотворение наизусть | Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |

**Форма проведения дифференцированного зачета - Опрос по билетам для татарской группы**

| | | |
|---|---|---|
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет № 1<br>1. “Бер рәхмәт мең бәләдән коткара” мәкаленең мәгънәсен аңлатырга.<br>2. Кол Гали. "Кыйссаи Йосыф" әсәренең идея-сәнгать үзенчәлекләре. Татар халкының рухи тормышындагы урыны турында сөйләгез.<br>3. Бер шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләгез | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет № 2<br>1.Мәкальләрнең асылын аңлатыгыз:<br>“Ипи-тоз – якты йөз” дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?<br>2. Татар халкының бөек язучысы Габдулла Тукайның тормыш юлы турында сөйләгез.<br>3. Бер шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләгез | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет № 3<br>1.Түбәндәге фразеологизмнарның мәгънәләрен аңлатыгыз:<br>Уттан качып ялкынга төшү.<br>Сүзне аяк астына салу.<br>Юрганга карап аяк сузу. | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |

| | | |
|---|---|---|
| | "Кеше күңеле пыяла, нык кагылсаң уала" мәкаленең мәгънәсен аңлатырга.<br>2. К. Насыйри – татар мәгърифәтчелегенең күренекле вәкиле турында сөйләгез.<br>3 . Бер шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләгез. | |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет № 4<br>1.Мәкальләрнең асылын аңлатыгыз:<br>Гәүдәсе зур берне егар, белеме зур меңне егар.<br>Шөгыльле- шөгылен күрсәтер, шөгыльсез- фигылен күрсәтер.<br>Һөнәрле үлмәс- һөнәрсез көн күрмәс.<br>"Бәйрәм ашы – кара каршы" дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?<br>2 .Г.Кутуйның "Тапшырылмаган хатлар" әсәрендә сезгә ошаган герой.<br>3. Бер шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләгез. | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет № 5<br>1.Түбәндәге фразеологизмнарның мәгънәләрен аңлатыгыз:<br>Телне аркылы тешләү.<br>Тел белән тегермән тарту.<br>Теленең очына чыга алмау.<br>"Бер рәхмәт мең бәләдән коткара" мәкаленең мәгънәсен аңлатырга.<br>2. Татар әдәбиятының классик язучысы Һ. Такташ иҗаты турында сөйләгез.<br>3. Бер шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләгез. | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |

| | | |
|---|---|---|
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет № 6<br>1.Мәкальләрнең асылын аңлатыгыз:<br>Эшчән бәхетне эштә табар, ялкау төшендә табар.<br>Данны эзләүче түгел, эшләүче таба.<br>Киңәшле эш таркалмас.<br>“Кеше күңеле пыяла, нык кагылсаң уала” мәкаленең мәгънәсен аңлатырга<br>2.Муса Җәлилнең “Кошчык” шигырендә ирек мәсьәләсе.<br>3.Бер шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләгез | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет № 7<br>1.”Бала итәктә чакта сөйдерә, итәктән төшкәч көйдерә“ мәкаленең мәгънәсен аңлатырга<br>“Астыртын эт өрми тешләр” дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?<br>2. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәре.<br>3. Бер шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләгез. | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет № 8<br>1. “Берәү өчен берәү-баганага терәү” мәкаленең мәгънәсен аңлатырга.<br>“Бирим дигән колына чыгарып куяр юлына” мәкаленең мәгънәсен аңлатырга.<br>2.Каюм Насыйриның “Кырык бакча” әсәре.<br>3. Бер шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләгез | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет № 9<br>1. “Кая барсаң да кара сакалың артыңнан калмый”мәкаленең мәгънәсен аңлатырга.<br>“Матурлык туйда кирәк, акыл көн дә кирәк” мәкаленең мәгънәсен аңлатырга.<br>2. Ф. Яруллин иҗаты турында сөйләгез. | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |

| | | |
|---|---|---|
| | 3. Бер шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләгез | |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет №10<br>1.Түбәндәге фразеолгизмнарның мәгънәләрен аңлатыгыз:<br>Әлифне таяк дип тә белмәү.<br>Үз бизмәне белән үлчәү.<br>Үзең утырган ботакны чабу.<br>“Берәү өчен берәү-баганага терәү” мәкаленең мәгънәсен аңлатырга<br>2.Драматург һәм режиссер . Г. Камал турында сөйләгез.<br>**3.** Бер шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләгез | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет №11<br>1.Түбәндәге фразеолгизмнарның мәгънәләрен аңлатыгыз:<br>Сүзе аяк астына салу.<br>Тормыш арбасын тарту.<br>Тыштан ялтырап, эчтән калтырау.<br>Агай-эне белән аш татлы” дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?<br>2. Г. Камал “ Банкрот” әсәренә анализ ясагыз.<br>3. Бер шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләгез. | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет №12<br>1. Мәкальләрнең асылын аңлатыгыз:<br>Чакырып килгәннең аты зур, сөеп килгәннең хакы зур.<br>Туган илнең кадерен читтә йөрсәң белерсең.<br>Олыласаң олыны-олыларлар үзеңне. | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |

| | | |
|---|---|---|
| | "Иренгән ике эшләр, саран ике түләр" мәкаленең мәгънәсен аңлатырга.<br>2.Татар халкының йолалары турында сөйләгез.<br>3.Бер шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләгез. | |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет №13<br>1. Мәкальләрнең асылын аңлатыгыз:<br>Бүредән курыксаң, урманга барма.<br>Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың.<br>Кунак булсаң, тыйнак бул.<br>Агай-эне белән аш татлы" дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?<br>2. Г.Камалнаң "Беренче театр".<br>3. Бер шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләгез | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет №14<br>1. "Ашар өчен яшәмә, яшәр өчен аша" дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?<br>"Ипи-тоз – якты йөз" дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?<br>2.Татар халкының дини бәйрәмнәре турында сөйләгез.<br>3. Үзегезнең яраткан шигырьне яттан сөйләгез | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет №15<br>1."Юлга чыксаң, юлдашың үзеңнән әйбәт булсын" дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?<br>"Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың" дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?<br>2. Казан мәчетләре турында сөйләгез.<br>3.Үзегезнең яраткан шигырьне яттан сөйләгез. | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |

| | | |
|---|---|---|
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет №16<br>1.“Тарга тар дөнья, киңгә киң дөнья” дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?<br>“Чит җирләрдә солтан булганчы, үз илеңдә олтан булсаңчы” дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?<br>2.Г. Тукай “ Печән базары , Яхуд яңа Кисекбаш” поэмасына анализ ясагыз.<br>3.Үзегезнең яраткан шигырьне яттан сөйләгез | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет №17<br>1. “Агай-эне белән аш татлы” дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?<br>“Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың” дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?<br>2. Хади Такташ “ Урман кызы” шигырьнә анализ.<br>3.Үзегезнең яраткан шигырьне яттан сөйләгез | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет №18<br>1.“Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың” дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?<br>“Ипи-тоз – якты йөз” дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?<br>2.Х. Такташның “ Мәхәббәт тәүбәсе” поэмасы.<br>3.Үзегезнең яраткан шигырьне яттан сөйләгез | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет №19<br>1. “Астыртын эт өрми тешләр” дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?<br>“Чирен яшергән- үлгән, бурычын яшергән- бөлгән” мәкаленеңмәгънәсен аңлатырга.<br>2. Х. Туфан “ Кайсыгызның кулы җылы”.<br>3.Үзегезнең яраткан шигырьне яттан сөйләгез. | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>________________ |

| | | |
|---|---|---|
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет №20<br>1. “Матурлык туйда кирәк, акыл көн дә кирәк” мәкаленең мәгънәсен аңлатырга.<br>“Кеше күңеле пыяла, нык кагылсаң уала” мәкаленең мәгънәсен аңлатырга.<br>2. М Җәлилнең тормыш юлы турында сөйләгез.<br>3.Бер шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләгез | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |
| ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж» | Билет №21<br>1.“Бирим дигән колына чыгарып куяр юлына” мәкаленең мәгънәсен аңлатырга.<br>“Иренгән ике эшләр, саран ике түләр” мәкаленең мәгънәсен аңлатырга<br>2.М. Җәлилнең “ Моабит дәфтәрләре” җыентыгы.<br>3.Бер шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләгез. | «Рассмотрено»<br>На заседании ЦК___<br>Председатель ЦК<br>_________________ |

**3.3. Показатели оценки результатов и критерии оценивания.**

Проверяемые результаты, показатели оценки результата

| **Результаты** | **Показатели оценки результата** |
|---|---|
| Понимать значения специфических особенностей творчества отдельных писателей этого периода. | Умение раскрывать особенности содержания и формы произведений татарской литературы с использованием основных понятий и терминов, приемов и методов анализа и интерпретации текстов, принятых в современном литературоведении |
| Овладение основными методами и приемами исследовательской и практической работы в области истории татарской литературы. | Умение ořеделять основные литературные течения и направления, выделяемые в татарской литературе |
| Владеть навыками сопоставительного анализа при выявлении соотношения восточной, русской классической и западной литературных традиций в произведениях татарских писателей. | Умение пользоваться основными тенденциями жанрово-стилевых поисков |

| | |
|---|---|
| Владение полученными знаниями в научно-исследовательской и других видах деятельности | Владеть научной и справочной литературой, библиографическими источниками и современными поисковыми системами |
| Овладение анализировать имеющиеся литературно-критические суждения по творчеству изучаемых писателей с выявлением собственной позиции. | Умение демонстрировать на практике владение ключевыми литературно-критическими письменными жанрами: аннотация, рецензия, обзор, реферат |

**Условия выполнения заданий:**
Место выполнения задания: учебный кабинет«Татарский язык и литература»
Максимальное время выполнения задания: 2 ак. часа.
Оборудование учебного кабинета:

1. Посадочные места по количеству обучаемых;
2. Рабочее место преподавателя.

Технические средства обучения:

1. Ноутбук
2. Магнитофон
3. Доска
4. Необходимая методическая и справочная литература (в.т.ч. в электронном виде)

**Основные источники**

1. Ганиева, Ф.А. Литература (татарская литература). 10 класс. В 2-х ч. / Ф. А. Ганиева, Д.М. Абдуллина, Ч.Р. Рамазанова. — Казань: Тат. книж. изд-во, 2016.- 239 с.
2. Закиев, М. З. Татарский язык. 10-11 кл.: учебное пособие / М. З. Закиев, Н. В. Максимов. – Казань: Тат. книж. изд-во, 2016-334с.
3. Фатхуллова, К. С. Давай говорить по- татарски:учебное пособие/ К. С. Фатхуллова, Ә. Ш. Юсупова, Э. Н. Денмөхәммәтова. — Казань: Тат. книж. изд-во, 2015. – 311 с.

*Интернет-ресурсы:*

1. tatartele.com.
2. «Ана теле»сайты – Anatele
3. «Белем.ру» - belem.ru
4. http://tt.wikipedia.org
5. tatar.com.ru
6. http://tatar.moy.su
7. tatyaz.flexum.ru
8. http://tatarplanet.ru
9. http://belem.ru
10. http://www.kitap.net.ru

Прошито, пронумеровано и скреплено печатью

________ листов

Директор ГАПОУ Сабинский аграрный колледж

_______________/ Бикмухаметов З.М/